• БӨЕК ҖИҢҮГӘ – 73 •

ФРОНТОВИК ХАТИРӘЛӘРЕ

*Бөек Ватан сугышының II дәрәҗәле Ордены иясе Харис хәзрәт Сәлихҗан истәлекләре.*

*4 бит*

• УРАЗА МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ •

УРАЗА ҺӘРКЕМГӘ ФАРЫЗМЫ?

*Уразаны нәрсә бозмый? Ураза тота алмаучыларга нишләргә?*

*7 бит*

• НӘСЫЙХӘТ •

ҺӘРКЕМ КОРЪӘН-ХАФИЗ БУЛА АЛА

*Изге Китапны ятларга теләүчеләргә мөфти киңәшләре.*

*10 бит*

• БУ КЫЗЫКЛЫ •

ГАЙБӘТ КАЙЧАН РӨХСӘТ ИТЕЛӘ?

*Кайсы очракларда һәм ни өчен шәригать гайбәт сөйләүне рөхсәт итә?*

*15 бит*

*№ 4 (273)* *Татарстан мөселманнары диния нәзарәте басмасы* *Раҗәб – Шәгъбан 1439*

*Апрель, 2018*

دين ومعيشت

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

# Шәгъбан аеның фазыйләтләре



## Хөрмәтле мөселман кардәшләребез!

Шәгъбан ае безгә Аллаһның рәхмәте булган Рамазан аеның якынлашуын хәбәр итә. Шәгъбанда Аллаһка якынаерга мөмкинлек бирелә, Аның рәхмәт ишекләре киңрәк ачыла, гөнаһлар ярлыкана, ә гыйбадәт кылу һәм изге гамәлләр өчен тагын да күбрәк савап бирелә. Аллаһы Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисләрендә әйтелгән: «Шәгъбан аеның калган башка айлардан өстенлеге – минем башка пәйгамбәрләрдән артыклыгым кебек үк».

Шәгъбан аеның өстенлеге – мөбарәк Бәраәт кичәсе. Хөрмәтле дин кардәшләребез! Исегездә тотыгыз, бу айда эшләнә торган изге гамәлләрнең әҗере күпкә арта һәм күкләргә бернинди тоткарлыксыз күтәрелә. Шуңа күрә сезне күркәм эшләр, гыйбадәтләр һәм тәүбә догалары кылырга чакырам. Аллаһы Тәгалә әҗер-савапларын биреп, Аның рәхмәтенә һәм ярлыкавына ирешергә язса иде!

**■ Татарстан мөфтие**
**Камил хәзрәт Сәмигуллин**

# Рамазан – кичерү, тәүбә итү һәм саваплар ае

**Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим!**

**Әссәләәмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәракәәтүһ!**

Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән Сезне ихлас күңелдән якынлашып килә торган изге Рамазан ае белән тәбрик итәм! Рамазан аенда чиксез бәхет-сәгадәт биргәне, ураза тоту, намаз һәм догалар уку, изге гамәлләр кылуны фарыз иткәне өчен Аллаһы Тәгаләгә безнең ихлас хәмед һәм шөкраналарыбыз ирешсә иде.

Рамазан ае – айларның солтаныдыр. Без бу изге айны түземсезлек белән көтеп алабыз һәм ул тәмамлану белән үк аны янә сагына башлыйбыз. Рамазан тәмамлангач кына, без яраткан Пәйгамбәребез Мөхәммәд (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) әйткән сүзләрнең асыл мәгънәсенә төшенәбез: «Изге Рамазан аен кешеләр кирәгенчә бәяли алсалар, аның бөтен ел буе дәвам итүен теләрләр иде», – ди ул. Чөнки мәгълүмдер ки, күп кенә хәдисләрдә фәрештәләрнең Раббыбыздан ураза тоткан мөселманның гөнаһларын ярлыкавын сораулары хакында әйтелә.

Сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) әйткәнчә, Ислам биш баганадан тора: иман китерү – шәһадәт, намаз, ураза, хаҗ һәм зәкәт. Ягъни Рамазан аенда ураза тоту Ислам дине нигезләренең берсе булып тора һәм җитди сәбәпсез Рамазан аенда ураза тотмау адәм баласының иманы камил түгеллеге хакында сөйли һәм гөнаһ санала.

**Мөхтәрәм дин кардәшләрем!** Уразаның асыл әһәмияте – кешенең үз нәфесләреннән өстен булуга ирешүе. Ураза яшәү дәртен изү, кешенең сәламәтлегенә зыян китерү өчен фарыз ителмәгән. Киресенчә, ул кеше организмының, ихтыяр көче һәм рухының ныгуына китерә, безне үзебезнең теләкләр һәм хисләр белән идарә итәргә һәм алар өстендә эшләргә гадәтләндерә.

Нәфесне тәрбияләүнең иң яхшы ысулы – ураза тоту. Ураза кешенең холкын камилләштерә һәм әхлак нигезләрен ныгыта. Ул безне Бөек Зат белән якынлаштыра, җаваплылык хисен арттыра, әдәплелек тәрбияли. Күңелләрне түбән хисләрдән һәм уйлардан арындыра, хуш күрелмәгән эшләрдән һәм кешеләргә карата начар мөгамәләдә булудан тыеп кала. Ураза күзләребезне хәрамга караудан саклый, телебезне ялганнан һәм яман сүзләрдән, колакларыбызны – гайбәттән, карыныбызны – хәрам ризыктан, кулларыбызны – яман эшләрдән һәм аякларыбызны хәрам артыннан чабудан саклый. Мөхәммәд Пәйгамбәр (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын): «Кем иманлы булган хәлдә, әҗерен Аллаһы Тәгаләдән өмет итеп, Рамазан уразасын тота икән, шуның бөтен элекке гөнаһлары гафу ителер», – дип әйткән. Ураза тотучыга: «Әй, Аллаһым, минем гөнаһларымны кичер», – дип әйтү хакы бирелә.

Ураза Аллаһы Тәгаләнең иң сөекле гыйбадәтедер. Һәр изге гамәл өчен савапларны фәрештәләр ирештерсә, ураза тотучыга бөек әҗерне Аллаһы Тәгалә Үзе җибәрә, чөнки ураза тоту Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен генә башкарыла. Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын алудан да зур бәхет бармы икән?

**Мөхтәрәм дин кардәшләрем!** Рамазан ае – кичерү, тәүбә итү һәм саваплар ае. Һәр мөселман шушы олы бүләктән тулысынча файдаланыр, дип өметләнәм. Бу изге ай гөнаһлардан арынуда ярдәм итсен, барчагызга да иминлек һәм күңел тынычлыгы китерсен!

Сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын): «Хактыр ки, Җәннәтнең Әр-Райян дигән капкасы бар. Кыямәт көнендә бу капкадан ураза тотучылар керәчәк. Һәм әлеге капкадан алардан башка бүтән беркем дә кермәячәк. Әйтелер: "Ураза тотканнар кайда?" һәм алар калкачак. Һәм әлеге капкадан ураза тотучылардан кала бүтән беркем дә кермәячәк. Алар анда кергәч, бу капка ябылачак һәм инде башка беркем аның аша кермәячәк», – дигән.

Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен тоткан уразаларыгыз һәм укыган догаларыгыз кабул булсын. Әмин!

■ **Камил хәзрәт Сәмигуллин, Татарстан Республикасы мөфтие**

# Коръән кыйссалары: «Сөекләләр һәм көнчеләр турында» *(башы, дәвамы 3 нче биттә)*

**Бу язмада мин иң маҗаралы һәм мавыктыргыч Коръән кыйссаларының берсе турында - Йосыф галәйһиссәләм турында бәян итәм. Аны үзенең бертуган көнче абыйлары коега ташлый. Аннары вакыйгалар ничек дәвам итә соң?**

## Коедан – йөрәк түренә

Йосыфның бәхетенә, коедан ерак түгел генә Мисырга юнәлә торган кәрван узган. Шул кәрваннан ике кеше Йосыфны табып алалар. Әмма коедан ул коллар, әсирләр сатыла торган базарга эләгә, аны Мисыр хакименең вәзире сатып ала. Үз балалары булмаганлыктан, аның йөрәгендә аталарга хас кайгырту хисләре уяна. Гадел, тәрбияле, югары әхлаклы, тәртипле Йосыф яңа гаиләдә дә, хәтта Мисырның хөкүмәт сараендагы кешеләр арасында да алмазга тиң яратылуга ия була, вакытлар узу белән вәзир янәшәсендә үзенең лаеклы урынын ала.

Әмма төп сюжет линиясе Йосыф белән вәзирнең Зөләйха исемле хатыны арасында үстерелә. Мисырның иң матур хатын-кызларының берсе булган Зөләйха кияүгә чыкканчы ук төш күрә. Ул төшендә ай нуры уза торган якты йолдызга әверелә. Әлеге төшнең Йосыф турында икәнен Зөләйха белми һәм төшне үзенчә юрый: вәзир тарафыннан кияүгә чыгарга ясалган тәкъдимгә уңай җавап кайтара. Сөюдән яну хисе соңрак килә… Аның йөрәгенә ире өенә алып кайткан акыллы, ягымлы, яшь матур егеткә тартыла.

Үз хисләре белән җәфаланган һәм бу хәлдән бернинди чыгу юлын күрә алмаган Зөләйханы хәтта җитмеш дөягә төяргә мөмкин булган кыйммәтле әйберләр дә шатландыра алмый. Ул, бернигә дә карамыйча, Йосыфка булган мәхәббәте өчен көрәшне дәвам итә.

## Бөек сынау

Зөләйханың җавапсыз мәхәббәте тиз арада кайгы-хәсрәт, борчусагышка үсә һәм аның акылыннан өстен чыга – ул үзенең матурлыгын сөйгәненең игътибарын яулап алуда файдаланырга уйлый. Бер тапкыр, иң матур күлмәген киеп, Зөләйха Йосыф галәйһиссәлащмне үзенә чакыра. Йосыф башын иеп аның алдында басып тора, ә ул гаҗәеп караш ташлый. Коръәндә аларның шушы очрашулары турында болай диелә: «Вәзир хатыны Зөләйха үз өендә Йосыфтан ялынып вә ялварып нәфесе теләгәнне үтәвен таләп итте вә барча ишекләрне бикләде һәм: «Ий Йосыф, кил минем яныма, мине мәхрүм итмә», – диде. Йосыф әйтте: «Бу эштән Аллаһка сыгынамын, тәхкыйк, тәрбиячем Газиз миңа хөрмәт күрсәтте, торачак җиремне күркәм кылды, инде мин аңа ничек хыянәт итим! Бу эшне кылсам залимнәрдән булырмын, әлбәттә, залимнәр Аллаһ газабыннан котыла алмаслар» («Йосыф» сүрәсе, 23 нче аять). Бу аятьтән аңлашыла ки, Йосыф галәйһиссәләм Зөләйханың тәкъдимен кире кага. Зөләйха үзенең матурлыгын, гүзәллеген Йосыфны гөнаһка алып бару өчен ничек кенә файдаланырга тырышмасын, бу эш мөмкин булмый. Зөләйхага: «Мин Аллаһтан куркам һәм үземнең Хуҗама хыянәт итмим», – дип әйтеп, ул үзе ишеккә таба юнәлә, ә аның йөрәге сагыштан сыкрый. Зөләйха, Йосыфның шундый килешкилбәтеннән кире кагылганнан соң, җәһәт адымнар ясый, аның күлмәген ертып ташлый, һәм шул мизгелдә булмәгә… аның ире килеп керә.

Коръәндә бу хакта түбәндәгеләр әйтелә: «Икесе дә ишекләргә таба йөгерделәр. Йосыф Зөләйхадан котылыр өчен йөгерде, Зөләйха Йосыфны чыгармас өчен артыннан йөгерде, Йосыфның күлмәгенең артыннан тотып үзенә тартты, күлмәк ертылды. Йосыф ишекләргә килгәндә бикле ишекләр Аллаһ кодрәте белән ачыла бардылар. Шулай куышып ишек алдына чыксалар, Зөләйханың ире Газизгә очрадылар. Зөләйха үзенең иренә әйтте: «Синең хатыныңа яман касд кылган кешегә җәзасы нәрсә булыр? Әлбәттә, төрмәгә бикләү яки рәнҗетә торган газап булыр» («Йосыф» сүрәсе, 25 нче аять). Вәзиргә якын булган кеше әлеге вакыйганы аңларга ярдәм итә: «Әгәр Йосыфның

# Коръән кыйссалары: «Сөеклеләр һәм көнчеләр турында»

*(дәвамы, башы 2 нче биттә)*

күлмәге ал яктан ертылган булса, Зөләйха сүзе дөрес булыр, Йосыф сүзе ялган булыр. Әгәр Йосыфның күлмәге арт яктан ертылган булса, Зөләйха сүзе ялган булып, Йосыф сүзе дөрес булыр» («Йосыф» сүрәсе, 26 нчы аять). Йосыфның гаепле булмаганына ышанган хәлдә, вәзир үз хатыныннан таләп итә: «Син Зөләйха тәүбә ит, гөнаһың өчен миннән гафу сора! Тәхкыйк, син хаталанучылардан булгансың» («Йосыф» сүрәсе, 29 нчы аять).

## Йосыф галәйһиссәләм янәдән төрмәдә

Әмма мәхәббәт өчпочмагыннан Йосыфка шулай да уңышлы котылу насыйп булмый. Хатынының хыянәтеннән интегүче вәзирне яңа һөҗүм көтә: Зөләйханың хисләре, булып узган вакыйгаларны яшерергә омтылыш булуга карамастан, Мисырның барлык почмакларында бу хәлләр гайбәт булып сөйләнә башлый. Һәм ул җитди адымга барырга карар кыла: Йосыфны күрсәтер өчен, затлы нәселдән булган хатын-кызларны өстәл янына җыя. Ул нәрсә буласын чамалый: аның матурлыгы кунакларга бик көчле тәэсир итә, алар аннан бер дә күзләрен ала алмыйлар, һәм җиләк-җимешләрне чистартканда, хәтта сизмәстән үзләренең кулларын кисәләр: «Аллаһ пакьтер, бу кеше түгелдер, бу һичкем түгел, мәгәр хөрмәтле фәрештәдер» («Йосыф» сүрәсе, 31 нче аять). Хатын-кызлар бердәм рәвештә Зөләйхага теләктәшлек күрсәтәләр.

Әмма Зөләйха үзе һәм вәзир әлеге мәхәббәт һәм гайбәт тарихыннан һичнинди башка котылу юлын күрмиләр: Йосыфны төрмәгә ябалар. Ләкин, ни генә булмасын, чынлыкта, Зөләйха югары әхлакка ия һәм бик тә зирәк хатын-кыз була. Әмма Йосыфка булган кайнар мәхәббәте аны аек акылдан, фикерләү сәләтеннән мәхрүм итә. Зөләйха аерылышуның авырлыклардан котылырга ярдәм итәчәгенә ышана, вәзир исә үз гаиләсенең намусын сакларга тели.

Йосыф галәйһиссәләм төрмәдә озак утыра. Ә Зөләйха һәм вәзир бу чакта «намус төрмәсендә» ябылып калалар: алар гаепсез кешене котыртуларын аңлыйлар. Зөләйха шулкадәр җәфалана ки, хәтта үзенең матурлыгын һәм яшьлеген югалта. Һәм бу аның үзенең нәфесе һәм Йосыфка карата булган хисләренә җавап кайтаруы була. Әмма күз яшьләре һәм ихлас күңелдән тәүбә итүе сәбәпле, ул әлеге гөнаһтан пакьләнә.

## Күптән көтелгән ирек һәм хаклыкның өскә чыгуы

Йосыф галәйһиссәләм үзенең хак юлга чакыру, киңәш бирү һәм инандыру эшчәнлеген хәтта иректә булмаган чакта да дәвам итә, ул төрмәне мәдрәсәгә әверелдерә. Монда аның төшләрне юрау сәләте дә ачыла.


Тәкъдиренә язганга күрә, Йосыф галәйһиссәләм белән тоткында бергә тагын Мисыр хакиме ялчысына якын торган кешеләр – эчемлекләр ташучы һәм пешекче була. Алар үзләренең төшләрен Йосыф белән уртаклашалар: берсе ничек итеп йөземне изеп суын алуны, ә икенчесе – башында ипи алып баруны һәм аны кошлар чукуын күрә. Йосыф сүзен кыска тота: «Берегез зинданнан чыгып әүвәлге урынында хәмер ясаучы булыр, әмма икенчегезне асарлар вә башын кошлар ашар. Сез сорадыгыз – мин җавап бирдем, әлбәттә, эш мин тәгъбир кылганча булыр» («Йосыф» сүрәсе, 41 нче аять).

Шулай килеп чыга да. Күпмедер вакыт узганнан соң, пешекчене үлем җәзасына тарталар, ә эчемлекләр йөртүчене гафу итәләр, төрмәдән чыгаралар һәм ул янәдән хакимнең ялчысы булып эшли башлый. Йосыф галәйһиссәләм белән хушлашып, ул аның турында хуҗасы алдында искә алырга вәгъдә бирә, әмма оныта һәм Йосыф төрмәдә берничә елга кала әле… Мисыр хакименең үзенә төшләр кергәнчегә хәтле…

Аларны юрау бернинди астрологларга, күрәзәчелек кылучыларга һәм акыл ияләренә дә бирелми. Бары онытылган тоткын гына барлык баш ватулардан азат итә – ул Йосыф булып чыга, бу хакта эчемлекләр йөртүче искә төшереп җиткерә.

– Ий Йосыф! Җиде ябык сыер җиде таза сыерны кабып йотканны, ә җиде коры башак җиде яшел башакны ашаганны ничек юрарга? Мин синең төш юравыңны тапшырачакмын, һәм сине төрмәдән чыгарырлар, – дип мөрәҗәгать итә аңа эчемлекләр ташучы.

Йосыф галәйһиссәләм хакимнең төшен юрый: «Җиде таза сыер һәм җиде яшел башак җиде ел муллыкта яшәүне аңлата. Аннары җиде ел ачлык һәм коточкыч корылык киләчәк. Беренче җиде елда күбрәк чәчегез, ә уңышны җыеп алу вакыты җиткәч, үзегезгә туклану өчен кирәк булган кадәрен җыеп алыгыз, ә калганын башакларда калдырыгыз һәм амбарларга кертеп урнаштырыгыз. Ә ачлык җиткәч, сез әлеге ашлыкны куллана алачаксыз. Җидееллык ачлыктан соң муллык еллары җитәчәк һәм кешеләр янәдән имин, бәхетле тормышка ирешәчәкләр».



Хаким Йосыф галәйһиссәләмнең хикмәтен югары бәяли һәм барлык кешеләргә аның гаепсез булуын игълан итеп, азат итә. Йосыфның гаебе булмавын аның төрмәгә ябылуына катнашы булучыларның барысы да раслый. Алар арасында Зөләйха да була. Ул бик тә ялварып үзенең җинаятен һәм Йосыфка булган мәхәббәтен аңлата: «Менә хәзер хаклык өскә чыкты, Йосыфның миңа якынлык кылуын мин үзем өстәдем, әмма Йосыф хыянәт итмәде, аның сүзләре хак» («Йосыф» сүрәсе, 51 нче аять). Ә Йосыф, үзенең югары әхлакый сыйфатларга ия булуы, алдан күрүчәнлеге һәм туры сүзле булуы сәбәпле, баш казначы итеп билгеләнә һәм… тол калган Зөләйхага өйләнә. Аңа Аллаһының рәхмәте белән яшьлеге һәм матурлыгы кире кайта.

## «Авырлыктан соң Аллаһы Тәгалә җиңеллек бирә»

Йосыф галәйһиссәләм үзе, Мисыр хакименең баш вәзире булып, барлык ил кешеләренең хөрмәтен казана. Йосыф галәйһиссәләмнең тырышлыгы белән Мисыр җиде еллык корылыкны имин рәвештә кичерә. Киресенчә, күрше дәүләтләр авыр хәлдә кала, анда яшәүчеләр, ачлыктан интегеп, Мисырга барырга омтылалар. Алар арасында Йосыфның Фәләстыйнда яшәүче абыйлары да була. Туганнар белән очрашу көтелмәгәндә була, һәм Йосыф галәйһиссәләм аларны гафу итә: «Бүген сезне гаепләп битәрләү юк, курыкмагыз, мин сезне хөкем итмим. Кылган гөнаһларыгызны Аллаһ ярлыкасын, Ул бик шәфкатьле вә рәхимле!» («Йосыф» сүрәсе, 92 нче аять).

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай ди: «Йосыф үзенең мәнзилендә ата-анасын хөрмәтләп тәхеткә утыртты, аннары Йосыфны зурлап шөкер йөзеннән барчасы сәҗдәгә егылдылар, вә Йосыф әйтте: «Ий атам, күп еллар элек күргән төшемнең тәэвиле ошбудыр, тәхкыйк, Раббым бу төшемне дөрес кылды вә Раббым миңа ихсан кылды, мине зинданнан чыгару белән вә сезне сәхрәдән Мисырга китерү белән минем белән кардәшләрем арасына шайтан вәсвәсә белән дошманлыкны салганы соңында, тәхкыйк, Раббым теләгән нәрсәсен шәфкать белән кылучы, әлбәттә, Ул белүче вә тиешенчә эш кылучы» («Йосыф» сүрәсе, 100 нче аять).

Аллаһының рәхмәте белән Йосыф барлык авырлыкларны имин уза һәм күркәм сыйфатлар, гамәлләр белән бүләкләнә: көч, байлык һәм хакимият. Аллаһы – бар нәрсәгә дә көче җитүче Зат. Ул һәрвакытта да Үзенә иман китергән, итагатьлелек күрсәткән, ихластан ислам диненә хезмәт иткән колларына булыша. Мөселманнарның бурычы булып иманлы булу, туры юлдан тайпылмау һәм ныклык күрсәтү тора. Мөселманнарны авырлыклардан соң һәрвакытта да иминлек һәм бәхетле тормыш көтә. Коръән безгә бу хакта турыдан-туры әйтә: «Ярлы вә авыр тормыштан соң Аллаһ тиздән дөньяда яки ахирәттә тормышны бай, иркен кылыр» («Талак» сүрәсе, 7 нче аять) һәм «Дөреслектә, файдалы булган җиңеллек авырлыктан соң» («Инширах» сүрәсе, 5 нче аять).

■ **Камил хәзрәт Сәмигуллин,**
**Татарстан Республикасы мөфтие**

# Фронтовик хатирәләре




Салихов Харис Салих улы (Харис Салихҗан) 1927 елда Татарстанның Балтач районы Чутай авылында туа. Авыл мәктәбендә укыган вакытында әтисе аны ислам гыйлемнәренә һәм гарәпчә укырга өйрәтә. Чутай җидееллык мәктәбен тәмамлаганнан соң Арча педучилищесына укырга керә. 1944 елда фронтка китә. Яу кырында күрсәткән батырлыклары өчен Ватан сугышының II дәрәҗәле Ордены һәм 20дән артык медаль белән бүләкләнә. Сугыштан соң Мәскәүдә һәм Казанда хокук саклау органнарында эшли. Гадел һәм профессиональ юрист буларак таныла. 1972 елда Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнгән. Казанның «Хәтер» мәчете имам-хатыйбы. 2017 елда Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды.

## «Аллаһ дигән сүз чыгарма, төрмәгә ябарлар»

Сугыш вакытында динне тыю булмады. 43-45 елларда бер генә частьтә дә бер генә кеше дә тыймады аны. Хәрби җитәкчеләр арасында Аллаһка мөрәҗәгать иткән, дога кылган кешене түбәнсетү дә, шул ук вакытта дога кылыгыз әле дип әйтүче дә булмады.

Унҗиде яшем тулганда – 1944 елны мине армия сафларына чакырып алдылар. Бер үземне генә түгел. Авылыбызның бөтен яше-карты безне сугышка озатып калды. Ул чактагы елашулар кичә генә булган шикелле. Әби миңа: «Бишмәтеңә «Ясин» сүрәсен тектем, югалта күрмә», – дигән иде. Дөрестән дә, мин аны югалтмадым, ул әле хәзер дә саклана... Яу кырында ярты ел гына булган кешемен, әмма аның һәр көне – йөрәктә.

1945 елның март аенда Венгриядә каты сугышлар булды. Без – гел алгы сафта. Үлем белән күзгә-күз очрашабыз. Балатон күле янында безне 3 сәгать тоташ бомбага тоттылар. Аны сүз белән генә әйтә, аңлата торган түгел. Фашист шулкадәр явыз, Гитлерның сайлап алынган гаскәре белән сугышабыз.

...Сазлыктагы түмкәкләр арасына кереп яшеренергә мәҗбүр булдык. Башны гына чыгарып ятабыз. Суык. Фашистлар безне бертуктаусыз бомбага тота. Иманы көчәеп китте күрәмсең, Сәгъдулла исемле иптәш малай: «Яшьтәш, үтерәләр бит, әйдә, укы әле», – диде. Мин укыйм. «Әлхәм» сүрәсен укыйм. Сәгъдулла тагын «укы!» ди, мин тагы укыйм... Укы да укы, диләр. Хәлем бетте, укый-укый арып та беттем. Аллаһның рәхмәте, безнең отделениедән берәү дә үлмәде, Кәримов Нургаян исемле солдатның гына аягы яраланды. Ә үлүчеләр бихисап күп иде. Әлеге вакыйгадан соң татар малайлары сизеп алды укысаң исән каласың икәнлеген. Хәтта моңа кадәр бөтенләй ышанмый йөргәннәре дә. Бу хәлдән соң болар күбрәк минем янга сырыша башлады.

Һәр сугышка керер алдыннан Сәгъдулла да, Нургали дә, башкалар да «укы!» диләр иде. Вена операциясе алдыннан Сәгъдулла әйтә: «Әйдә, яшьтәш, намаз укыйк», – ди. Бөтен бер фронт яуга әзерләнгән вакыт бу. Без, сугышка әзерләнүчеләр – 17 яшьлек, 40-50 килолы малайлар инде. Күбебез русча да рәтләп белми. Дөресен әйтергә кирәк, безне килүгә үк өлкәнрәкләргә беркеттеләр. Русларга. Алар барысы да йә коммунист, йә комсомол.

Вена операциясендәге бурычыбыз алдагыларына караганда катлаулырак иде. Әзерлегебезне тикшереп карарга булдылар. Ә без – радистлар. Сәгъдулла радиостанция белән эшли алмады, каналга керә алмады. Старшина әйтә: «Син бит бернәрсә дә белмисең. Запас полктан үттеңме?» – ди. «Үттем», – ди Сәгъдулла. «Анда нишләдең?» – ди. «Шапком каша кушал», – ди бу. Запас полкта һәр солдатта кружка, кашык бар, ләкин савытлар юк иде. Чиләк белән аш алып киләләр. Аны кружкага салып бирәләр. Гел су гына инде ул, аш дип аталса да. Бер үк вакытта «икенче блюдо» дигәнен дә тараталар, ә аныСын салырга урын юк. Шул сәбәпле без бүрекләрне тезеп куя идек. Аңа бер кашык тары боткасы салалар. Үз бүрегеңдәгесен ашамыйсың әле, башка солдатныкы эләгә... Шуңа күрә дә Сәгъдулла «шапком каша кушал» диде старшинага.

Хаклыкны әйтергә кирәк, безнең гаскәрдә сайлап алынган кешеләр, бары тик комсомоллар һәм коммунистлар гына тупланган иде. Иң түбән белем – 9 класс. Без мөселманнар бит. Киткәндә әти миңа бик нык кисәтеп: «Аллаһ дигән сүз чыгара күрмә, төрмәгә ябып куярлар», – дигән иде. Шулай ук: «Үзеңә кыен чакта гына түгел, һәрвакыт Аллаһка ялвар, дога кыл!» – дип тә нәсыйхәт бирде. Әтинең шул сүзләрен гел күңелдә тоттым.




## Намаз укысаң – үлмисең!

Апрель аенда Вена операциясендә катнаштык. Без бер батальонда 30лап татар малае идек. Әйткәнемчә, малайлар: «Әйдәгез, операция алдыннан намаз укыйк», – диделәр. Һәр солдатта плащ-палатка бар, намазлык урынына шуны җәябез. Мин – имам. Малайлар мин нишлим, шуны эшли. «Намаз укысаң, үлмисеңме?» – диләр. Мин әйтәм: «Үлмисең. Ихлас ят та, Аллаһтан сора». Сәҗдәгә яткач малайлар «йә Аллаһ, йә Аллаһ...» дип елыйлар. Бик җитди хәрби операциягә әзерләнәбез бит. Бертуктаусыз комсомол җыелышлары бара. Бертуктаусыз үгетләү бара. Бертуктаусыз аңлату бара... Сугышырга өйрәтәләр. Ә без намаз укыйбыз шушы өйрәтүләрдән бушаган арада. Командирларга күренеп түгел инде, әлбәттә, качып кына. Кая инде ул күрсәтеп гыйбадәт кылу?! Берсендә мине өлкән сержант Сорокин күреп алды:

– Кил әле монда. Фамилияң ничек? – диде.

– Кызылармеец Салихов.

– Сез нишлисез анда?

– Кайда?

– Куаклар арасында нәрсә пышылдыйсыз?

– Намаз укыйбыз.

– Нәрсә ул намаз?

– Намаз – ул мөрәҗәгать.

– Кемгә?

Эчтән генә әйтергә уйлыйм, Иосиф Виссарионович Сталинга дип. Әмма күңелне «шәп чыкмас бу» дигән уй били. Ә Аллаһка мөрәҗәгать итәбез дип әйтергә куркам. Шулай ни әйтергә белми тордым да, бармагымны күккә күтәреп:

– Әнә, анда, өстә утыручыга, – дидем.

– Богу что ли?

– Так точно. Богу.

Шуннан соң, Аллаһның рәхмәте, бу миңа:

– Ә нәрсә сорыйсыз? – диде.

– Без, иптәш Сорокин, кызылармеец Салихов операция вакытында үлмәсен дип сорыйбыз.

– «Тагын нәрсә сорыйсыз?» – ди бу. Мин берәмләп бөтен татар малайларының исемен атап чыкканнан соң: «Пашка үлмәсен дип тә сорыйбыз, дөрес, аның алласы бүтән», – дидем. Миңа аптырап карады да: «Ничек бүтән?» – ди. Мин аңлатып күрсәттем инде русларның үз алласы, татарларның үз алласы булуын. Ә ул миңа «Яхшы итеп исеңдә калдыр, синең үз аллаң юк! Сезнең Аллаһ та, безнең бог та бер үк затны аңлата» димәсенме?! Менә сиңа өлкән сержант, коммунист! Ул һаман төпченүен дәвам итте әле. Шуннан соң мин аңа: «Ә без тагын операция вакытында иптәш Сорокин үлмәсен дип тә сорыйбыз», – дидем. «Чынлапмы?» – диде дә елый башлады. Мине кочаклап елады.

Урыс малайларының Библиядән язып алынган догалары бар иде. Ә кайберләре кесәләрендә икона да йөртте. Шуны кулларына алып «спаси нас бог» дип дога кылалар иде. Мин: «Ничек безгә дин мәсьәләсендә ирек бирәләр икән?!» – дип аптырый идем. Бер кеше тыймый, әле яклыйлар да.

■ **«Мөселманнар Бөек Ватан сугышында» китабыннан**

# «Бу кичтә күбрәк гыйбадәт кылмасагыз, Кыямәт көнендә үкенерсез»




Пәйгамбәребездән (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын): «Рамазан уразасыннан соң нинди ураза иң кыйммәтле санала?» – дип сораганнар. Ул: «Рамазан хөрмәтенә шәгъбан аенда тотылган уразалар», – дип җавап бирә. Быел шәгъбан ае 16 нчы апрельнең ахшамыннан 15 нче майның ахшамына кадәр дәвам итә.

## Бәраәт кичәсе

Шәгъбан аенда көн-төннәр арасында гыйбадәт кылучыга бәрәкәте күп булган, әҗер-саваплары да олы булган бер кичә бар. Бәраәт кичәсе шәгъбан аеның 14 нче кичәсеннән 15 сенә каршы кичтә була, ягъни быел ул 30 нчы апрельдән 1 нче май көненә туры килә. Бу кичәнең фазыйләте хакында Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгалә Үзенең сөекле китабы Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«Кеше өчен кирәк нәрсәләрнең барчасын ачык итеп бәян итә торган Коръән белән ант итеп әйтәмен. Чыннан да, Без ул Коръәнне мөбарәк бер кичтә иңдердек. Без ул Коръән белән имансызларны куркытучы булдык».**

«Духан / Төтен», 44:2-3

Бер хәдисендә Мөхәммәд (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын): «Бәраәт сезнең өчен зур форсаттыр, чөнки ул – билгеле кич, шәгъбан аеның 15 нче көненә каршы кич. Кадер кичәсе Бәраәт кичәсеннән зуррак булса да, аның кайсы кич булуын белү мөмкин түгел. Бу кичтә күбрәк гыйбадәт кылыгыз, кылмасагыз, Кыямәт көнендә үкенерсез», – дип әйтә.

## Бу нинди фазыйләтле кичә?

Янә мондый хәдис билгеле: «Шәгъбанның 15 нче кичәсендә Җәбраил фәрештә килде һәм: «Ий Мөхәммәд, гафил булма, бу кичә рәхмәт ишекләре ачыла торган кичәдер. Тор, кулыңны күтәреп дога кыл, изгелекләр телә!» – диде. Мин: «Ий Җәбраил! Бу нинди фазыйләтле кичә?» – дип сорадым. Җәбраил болай җавап бирде: «Бу кичәдә 300 рәхмәт ишеге ачылыр. Аллаһы Тәгалә һәр мөселман бәндәсен ярлыкар. 10 төрле бәндәне, тәүбә итмәсәләр, ярлыкамас: 1) сихерче; 2) күрәзәчелек белән шөгыльләнүче; 3) мөселман белән үпкәләшеп сөйләшмичә йөрүче; 4) бер-беренә ачу тотучы; 5) исерткеч эчүче; 6) зиначы; 7) адәмнәргә табыш белән акча бирүче; 8) ата-анасын рәнҗетүче; 9) үзенең туганлык җепләрен өзүче; 10) нахакка кеше үтерүчене. Әгәр бу эшләрне ташласалар, Аллаһы Тәгалә аларны ярлыкар».

## Кемнәрнең гөнаһлары ярлыканыр?

Пәйгамбәребез: «Мин бу кичәдә уяу тора идем. Кичәнең дүрттән бер өлеше үткәч, Җәбраил килде һәм: «Ий Мөхәммәд, башыңны күккә таба күтәр!» – диде. Күтәрдем һәм шуларны күрдем: күк ишегендә бер фәрештә бардыр, ул болай дип әйтәдер: «Бу кичәдә Аллаһы Тәгаләне искә алучы, зикер әйтүче бәндәгә сөенеч булсын». Икенче ишектә бер фәрештә бардыр, ул нида кыла, ягъни болай дип кычкыра: «Рөкүгъ кылган бәндәгә сөенеч булсын!» Өченче ишектә янә бер фәрештә нида кыла: «Бу кичәдә түбәнчелек белән намаз кылучы бәндәгә сөенеч булсын!» Дүртенче ишектә фәрештә нида кыла: «Бу кичәдә догалар кылып, хаҗәтләр сораган бәндәгә сөенеч булсын!» Бишенче ишектә бер фәрештә нида кыла: «Бу кичәдә Аллаһы Тәгаләнең газабыннан куркып елаган бәндәгә сөенеч булсын!» Алтынчы ишектә бер фәрештә нида кыла: «Бу кичәдә Коръән укучы бәндәгә сөенеч булсын!» Җиденче ишектә бер фәрештә нида кыла: «Әй, бармы хаҗәт сораучы? – Догасы кабул булыр. Бармы «әстәгъфируллаһ» дип әйтүче? – Барча гөнаһлары ярлыканыр. Таң атканчы бу ишекләр ачык булыр», – дип сөйләгән.

Ислам дине галимнәре аңлатуларына караганда, Кадер кичәсеннән соң изге булган кичә – Бәраәт кичәседер. Бәраәт кичәсеннән башлап, мөселманнар Кодыс шәһәренең Әл-Әкъса мәчетенә карап түгел, Мәккә шәһәрендәге Әл-Хәрам – Кыйблага карап намаз кыла башладылар.

Бу турыда Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«(Ий, Мөхәммәд) чыннан да, Без синең күккә карап торганыңны (хәбәр көткәнеңне) күрәбез. Хәзер Без Кыйбланы син бик тә риза булган тарафка күчерәбез. Йөзеңне изге мәчет (Кәгъбәтуллаһ) тарафына юнәлдер. (Ий, мөселманнар) кайда гына булсагыз да, йөзләрегезне шул Кыйблага юнәлдерегез. Шик юк ки, китап әһелләре (яһүдләр һәм христианнар) бугамәлләрнең Аллаһтан килгән чынбарлык икәнен бик яхшы белә. Аллаһ аларның ни кылганнарыннан хәбәрсез түгел».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:144

Бу кичне Аллаһы Тәгалә кояш чыкканчыга кадәр дөнья галәменә рәхмәт күзе белән карар, вә әйтер: «Юкмы гафу сораучы, аны гафу итәрмен, юкмы авыру кеше – шифасын бирермен, юкмы ризык сораучы, аны ризыкландырырмын».

Гата ибне Ясәр әйтүенчә, бу кичәдә бөтен мәхлукларның 1 еллык ризыклары, байлык вә ярлылык хәлләре, дөньяга бәйле дәрәҗәләре языла. Яңа туачак һәм бу ел эчендә вафат булачак кешеләр ошбу кичтә билгеләнә.

***

Без, адәм балалары, үлемнең кайчан, нинди мизгелдә киләсен белмибез! Газиз дин кардәшләрем! Мөхәммәд пәйгамбәр (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) әйткәнчә, Бәраәт кичәсе – догалар вә теләкләр кичәсе, кире кайтарылмый торган кичәдер. Бу кичәдә кылынган намазга саләтулхайр, ягъни «хәер намазы», дип әйтәләр. Ул 12 рәкәгатьтән 100 рәкәгатькә кадәр. Көндез мохтаҗларга сәдака бирү, ураза тоту, вә кичәне гыйбадәттә уздыру бик саваплы. Бу кадәр саваплар эшләргә мөмкинчелегебез булгач, сөенеп-сөенеп Коръән, намаз укыйк! Мөхәммәд пәйгамбәргә салават әйтеп, ата-аналарыбызга, барча мөэмин мөселманнарга, остазларыбызга хәер догалар кылыйк!

**Рөстәм хәзрәт Хәйбуллин,**
**Буа районы «Мәлик» мәчете имам-хатыйбы**

# Ураза тотсаң, гөнаһлардан арынырсың

Пәйгамбәребез Мөхәммәд (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын): «Көннәрнең олысы – җомга көне, ул ике гает, Гарәфә, Гашүрә көннәреннән дә олуграк. Кичәләрнең олысы – Кадер кичәсе, айларның олысы – изге Рамазан ае», – дип әйткән.

Нәрсә соң ул ураза? Ни өчен без аны тотабыз? Кемгә кирәк ул? Без уразаны Раббыбыз ризалыгы өчен дип тотабыз. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримнең «Әл-Бәкара» сүрәсенең 183 нче аятендә:

**«Әй иман китергән бәндәләр, сездән элекке кавемнәргә фарыз булган шикелле, сезгә дә ураза фарыз булды»,** – дип, уразаның фарызлыгын белдерде.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә бәндәләргә төрлечә эндәшә. Ә бу аятьтә, ураза турында әйткәндә: «Әй иман китергән кешеләр», – ди, чөнки Раббыбыз белә: ураза тоту иман китермәгән һәм иманы зәгыйфь булган кешенең көченнән килми. Кайберәүләр вакытым юк, эшем күп дип, юк сылтауны бар итә. Без: «Ләәә иләәһә илләллааһ Мүхәммәдүр Расүүлүллааһ», – дип, үз иркебез белән иман китереп, иман кәлимәсен әйткәч, мөселман булабыз. Шуннан соң безнең өстебезгә иманны яхшы белү, биш вакыт намаз, елга бер ай ураза, зәкәт, хаҗ шикелле фарызлар йөкләнә.

Ураза – шушы фарызларның берсе. Үзен мөселман дип таныган кеше ураза тотарга тиеш. Сәламәтлеге өчен, ябыгыр өчен түгел, Аллаһ ризалыгы өчен дип. Әгәр без уразабызны шулай тотсак, Хак Тәгалә кабул итеп, ураза гыйбадәтеннән җибәрсә – калганын Раббыбыз Үзе белүче. Әгәр без сәламәтлегебезне генә уйласак яки авырлыгыбыз кимесен дип кенә ураза тотсак, моның файдасы фәкать дөньялыгыбыз өчен генә була. Аллаһ сакласын! Кеше күрсен, башкалар мине уразалы дип әйтсеннәр өчен генә йөрсәк, монысы бигрәк тә гөнаһлы. Адәм баласы ике асылдан гыйбарәт. Анда нәфес бар – хайвани асыл һәм акыл, аң бар – фәрештәләрдән килгән асыл. Адәм баласының бөтен яшәеше шушы ике асылының көрәшеннән гыйбарәт. Гомер буе бездә нәфес белән аң көрәшә. Аллаһы Раббыбыз Коръәни Кәримдә, «Әт-Тин» («Инҗир агачы») сүрәсенең 4 нче аятендә болай ди:

**«Мин акыл биреп, сезне бөтен мәхлукаттан өстен иттем».**

Үзенең акылы, аңы белән нәфесен җиңә алучы кеше Аллаһы Тәгалә хозурында фәрештәләрдән дә өстен булыр.




Аллаһы Раббыбыз Коръәни Кәримдә «Әли Гыймран» сүрәсенең 133 нче аятендә:

**«Яхшылык эшләргә, тәүбә кылырга ашыгыгыз, җәннәткә ашыгучылардан булырсыз»,** – ди.

Без менә шушы айда яхшылык эшләргә ашыгырга тиеш. Үзебезнең күңелебезне, калебебезне чистартырга, яхшы сүзләр сөйләргә, гайбәткә кермәскә, ялганламаска тырышырга тиеш.

Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) болай дип әйткән: «Кем уразалы була торып та ялган-гайбәттән тукталмаса – аның ач йөрүеннән берничә файда юк». Әгәр телебезне начар сүздән, күңелебезне бозык уйдан сакламасак, гайбәттән тыела алмасак, ураза тотуыбыз гади бер ач торуга гына кайтып кала. Аның Аллаһы Тәгалә каршында да, бәндәләр алдында да кыйммәте булмый. Сәхәр ашап, көне буе хәләл булган икмәк белән судан да тыелуыбыз безгә ураза тотуыбызны искә төшереп тору өчен генә кирәк. Ураза икәнен исенә төшергәч, кеше үзен бөтен төр бозыклыктан сакларга тиеш. Уразаның асылы ул – кешенең яхшылык эшләргә омтылуы, башкаларга җылы сүз, яхшы мөгамәлә белән булышуы, бүтәннәрне кайгыртуы һәм бер-берсен гафу итүе.

Аллаһы Раббыбыз Коръәни Кәримдә, «Әли Гыймран» сүрәсенең 134 нче аятендә:

**«Ачуыгызны эчкә алыгыз, дошманнарыгызны гафу итегез, әлбәттә, Аллаһы Тәгалә каршында сөйкемле бәндәләрдән булырсыз»,** – ди.

Рамазан аенда ураза тотканда без матур әхлакка, гүзәл холыкка ирешергә тиеш. Кем дә булса берәүгә үпкәләп йөрсә – ул кешене кичереп, аның бәхиллеген алсын.

Хәтта безгә ниндидер начарлык эшләгән кешеләр турында да без яхшы сүзләр генә сөйләргә тиеш. Инде бу да көчебездән килмәсә, башкаларның начар гадәтен әйтми калу да яхшы булыр.

Хәләл ризыклардан, эчемлекләрдән тыелып, телләребезне гайбәттән саклап, күңелләребезгә пакь уйлар салып йөрсәк, бәлки Аллаһының рәхмәте булып, ел буе күңел сафлыгына ирешербез. Истә тотыйк! Мөселманга гайбәт сөйләү дә, кешегә зыян кылу да хәрам санала.

Рамазан ае – айларның солтаны, патшасы, ул мөэмин мөселманнарга чистарынырга мөмкинлек бирә торган ай. Кыямәт көнендә адәм балалары яңадан кубарылгач, алар ач булыр, эчәселәре килер, диелгән. Без бу дөньяда кайсыбыз егерме, кырык ел, кайсыбыз илле, сиксән, туксан ел яшибез. Шушы еллар өчен Аллаһы Тәгалә хозурына барып, җавап бирәсебез бар. Аллаһы Раббыбыз Коръәни Кәримдә болай ди:

**«Бу җирдә яшәгез, кәсеп итегез, эшләгез, әмма Аллаһы хозурына барасыгызны онытмагыз».**

«Мүлек / Патшалык», 67:15

Үзебезнең Раббыбыз хозурына барасыбызны Рамазан аенда бигрәк тә еш исебезгә төшерергә тиешбез. Дөньяда яшәгән кыска гына гомеребез өчен илле мең ел Аллаһы хозурында җавап тотасыбызны онытмаска кирәк. Адәм балалары каберләреннән ашыйсылары килеп, гаҗиз булып кубарылырлар. Шул вакытта Рамазан ае: «Йә, Раббым, менә бу бәндәң мине Рамазан ае дип хөрмәтләде, мине – Рамазан аен – муафыйк рәвештә үткәрде. Бүтән кешеләр ашапэчеп йөргәндә аның иреннәре сусаудан ярылган иде, йөзләре ачлыктан саргайган иде. Йә, Раббым, шушы бәндәңнең тамагын тук ит», – дип Аллаһыдан сорар. Хак Тәгалә фәрештәләргә боерык бирер: **«Йә, фәрештәләрем, шушы бәндәмнең тамагын тук итегез»,** – дип әйтер. Рамазан аенда ураза тоткан кешеләр каберләреннән хуш ис белән кубарылыр, фәрештәләр аларның тамагын туйдырып, сөаль мәйданында вакытта алар ачлык һәм эчәсе килүнең нәрсә икәнен белмәс.

Без үндүрт-унбиш яшьләребездә балигъ булсак, 75 яшькә кадәр яшәсәк, безгә 60 ел ураза фарыз була. 60 елга без алтмыш ай көндез ашамыйча торабыз, ягъни биш ел без Аллаһы ризалыгы өчен көндез ашаудан ваз кичәбез. Ә Раббыбыз шуның өчен Кыямәт көнендә илле мең ел буе сөаль мәйданында безнең тамагыбызны тук итә. Әле моннан тыш безгә шушы гыйбадәтләребез бәрабәренә Аллаһы Тәгалә җәннәтне дә насыйп итә.

Рамазан аенда ураза тотарга тырышуның икенче сәбәбе дә бар. Пәйгамбәребез: «Рамазан аенда җәннәт капкалары ачык булыр, җәһәннәм капкалары бикле булыр, шайтаннар чылбырда булыр», – ди. Димәк, шайтаннар безгә вәсвәсә сала алмый, Рамазан аенда безгә изгелекне эшләү җиңелрәк һәм бу айда эшләгән изгелеккә савап 700 дәрәҗәдә артыграк. Шуңа күрә мөселманнар зәкәтләрен дә Рамазан аенда биреп калырга тырыша.

Газиз дин кардәшләрем! Шушы айга кергәнбез икән, аны изге гамәлләр белән үткәрик. Коръән аятьләре укыйк, кино-тамашаларыбызны беразга калдырып торыйк. Хәлебездән килгәнчә мәчеткә, тәравих намазларына йөрик. Кадер кичәсендә гыйбадәт кылу – мең ай гыйбадәт кылуга тиң. Бу турыда Коръән аяте дә бар. Мең ай ул – 83 ел диган сүз.

Раббыбыз Аллаһы Тәгалә хәерле сәламәтлекләр биреп, Рамазан айларыбызны да Үзенә муафыйк булганча изгелектә үткәрүләребезне насыйп итсә иде, чөнки акылыбызның зәкәте намаз булса, сәламәтлегебезнең зәкәте – ураза. Сәламәт булмаган, авыру кешегә ураза фарыз түгел. Сәламәт килеш изге айны каршылаганбыз икән, Аллаһы Раббыбыз аны изге гамәл-гыйбадәтләр белән үткәрүебезне насыйп итсә иде.

**Җәлил хәзрәт Фазлыев,**
**Татарстан**
**Республикасының**
**баш казые**

# Ураза һәркемгә фарызмы?

Кайбер бәндәләргә Аллаһы Тәгалә җиңеллек бирә, ураза тотмаска рөхсәт итә. Мәсәлән:

1. Авыру кешеләр ураза тотмыйлар. Хасталарыннан арынгач, сәламәтләнгәч, уразаларын дәвам итәләр. Авыру вакытында тотылмаган уразаларын Рамазан аеннан соң, сәламәтләнгәч, тоталмыйча калдырган көннәрен тотып бетерәләр.

2. Рамазан аенда сәфәрдә булган кешеләргә дә ураза тоту – фарыз, ваҗиб түгел. Сәфәрдә булып, уразаларын тота алмаган кешеләр, шулай ук Рамазан ае үткәннән соң, башка айларда ничә көн калган булса, шуларны көнен көнгә тотып бетерәләр, ягъни каза кылалар.



3. Бала көткән яки бала имезгән хатыннар, үзләренең яки балаларының сәламәтлекләренә зыян килүдән курыксалар, уразаларын тотмаслар. Әгәр ураза баласы һәм үзе өчен зыянлы булмаса, уразасын дәвам итә. Мондый чакта уразаларын тота алмаган хатыннар, бу хәлләре беткәч, көнен көнгә тотып бетерәләр, ягъни каза кылып, өсләреннән төшерәләр.

4. Хәез (күрем) вакытында да хатын-кызлар ураза тотмыйлар. Әмма Рамазан гаетеннән соң, ничә көннәре калган булса, шуларны каза кылып тотып бетерәләр.

5. Картлык зәгыйфьлеге яки озакка сузыла торган (хроник) авыруы булу сәбәпле, ураза тотарга көче җитмәгән кешеләргә ураза тотмаска рөхсәт бирелә. Бу кешеләр тота алмаган көннәре кадәр фидия бирерләр. «Фидия» – бер көн иртә-кич бер ярлыны туйдырырлык акча. Акчасы һәм малы булмаган ярлылар өчен фидия бирү мәҗбүри түгел. Алар ураза тота алмаганнары өчен Аллаһы Тәгаләдән гафу сорарлар.

Шушы сәбәпләрдән уразаларын тота алмаган кешеләр: «Дин ягыннан миңа рөхсәт бар», – дип, уразалы кешенең алдында ашап-эчмәсләр, уразаны һәм ураза тоткан кешеләрне хөрмәт итәрләр.

■ **Илдус хәзрәт Фәизнең «Ураза тәртипләре» китабыннан**

# Уразаны нәрсәләр бозмый?

1. Онытып ашаган яки эчкән кешенең уразасы бозылмас. Бу кешенең ураза тотканы исенә төшсә, яисә башка кеше аңа моны хәтерләтсә, шул вакытта ашау-эчүне ташлап, авызын чайкап, ният кылып, уразасын дәвам итәр.

2. Тәһарәт алганнан соң авызда калган юешлекне йоту уразаны бозмас.

3. Авызга кергән тузан яки төтен уразаны бозмас.

4. Кеше үзенең төкереген йотса, уразасы бозылмас.

5. Теш арасында калган борчактан кечкенә аш кисәгеп йоту уразаны бозмас.

6. Щетка белән тешләрне чистарту, паста белән булса да, уразаны бозмас.

7. Бик зарур булган вакытта мунчада юыну яисә диңгезгә кереп коену уразаны бозмас. Ләкин авыз белән борынга су кертмәскә кирәк.

8. Күзгә сөрмә тарту һәм кан алдыру уразаны бозмас.

9. Сәхәрдән соң ятып йоклаган һәм, төшләнеп, җөнеб булган кешенең уразасы бозылмас. Бу кеше, уянгач, госел коеныр һәм уразасын дәвам итәр.

10. Чәчәк яисә хуш исләрне иснәү дә уразаны бозмас.

11. Үз ирен яки үз хатынын, яки баласын үпкән кешенең уразасы бозылмас (ләкин ир белән хатын үбешеп, теләк кузгалырлык булса, үбешергә ярамас).

■ **Илдус хәзрәт Фәизнең «Ураза тәртипләре» китабыннан**

# Әгәр кеше косса, аның уразасы бозыламы?

Косу ике төрле була.

1. Ашказаны бозылу, күңеле болгану сәбәбе белән үзеннән-үзе косу.

2. Бугазга бармакны тыгып яки башка берәр сәбәп белән үзеңне мәҗбүри костыру.

Әгәр косу үзеннән-үзе барлыкка килсә, шуңа игътибар итәргә кирәк: әгәр косык авызга тулмыйча, аз гына булып, үзеннән-үзе кире ашказанына төшеп китсә, бердәм фикер нигезендә, уразаны бозмас. Ләкин эчкә кире кертелгән очракта, Имам Мөхәммәд фикеренчә, ураза бозыла. Имам Әбү Йосыф фикеренчә, бозылмый. Чөнки бу, аз булганга күрә, тәһарәтне бозмаган кебек, уразаны да бозмый.

Әгәр косык авыз эченә тулып, кире ашказанына төшеп китсә, Имам Әбү Йосыф фикеренчә, ураза бозыла. Чөнки авыз тулы косык тәһарәтне боза. Имам Мөхәммәд фикеренчә, бозмый. Ләкин бу косыкның бер өлеше яки бөтенесе дә үзеннән-үзе түгел, махсус йотып җибәрү нәтиҗәсендә кире ашказанына төшерелсә, бердәм фикер буенча, ураза бозыла.

Әгәр косык махсус чыгарылса, шуңа игътибар итәргә кирәк: авыз косык белән тулса, ураза бозыла. Әгәр косык авызны тутырмыйча, аз гына булса һәм үзеннән-үзе кире төшеп китсә, имам Мөхәммәд фикеренчә, ураза бозыла. Әбү Йосыф фикеренчә, бозылмый.

Косык ашказанына кире төшеп киткән очракта, имам Мөхәммәд фикеренчә, бер риваятьтә Әбү Йосыф фикеренчә, ураза бозылмый.

Әбү Йосыфтан тапшырылган башка риваять буенча, ураза бозыла.

■ **Камил хәзрәт Сәмигуллинның «Ураза» китабыннан**

# Уразадагы кешегә мисвәк кулланырга ярыймы?



**Җавап:** Көннең башында яки ахырында мисвәк куллану мәкруһ түгел. Киресенчә, мисвәк куллану сөннәт гамәл була. «Кифайә» исемле әсәрдә бу хакта болай диелгән: Әбү Һөрайра (Аллаһ аннан разый булсын) риваять иткән бер хәдистә Расүлуллаһ (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын): «Мисвәк – сөннәт. Мисвәкне көндез үзегез теләгән вакытта кулланыгыз», – дип әмер иткән (Әбү Нугайм, «Хилйәтүл әүлия», 3/49; Дәйләми, Фирдәүс, Нәбхани, «Әл-Фәтхул Кәбир», №7044, 1/649).

■ **Камил хәзрәт Сәмигуллинның «Ураза» китабыннан**

# Ураза тота алмаучыларга нишләргә?

Ураза тотарлык хәле булмаган озак авырган кешеләр һәм бик олы яшьтәге кешеләр уразаның төшереп калдырылган һәр көне өчен фидия түлиләр.

Фидиянең күләме нәкъ фитр сәдакасы шикелле хисаплана (2018 елга фидия һәм фитр сәдакасының күләмен Рамазан алдыннан **dumrt.ru** сайтыннан яки мәчет имамнарыннан белергә мөмкин булачак). Фидияне үзең теләгәнчә бер генә фәкыйрь кешегә бирергә яисә берничә кешегә таратырга да мөмкин.

Әгәр мөселман кешенең фидия өләшергә көченнән килми икән, ул вакытта Аллаһтан гафу теләргә тиеш.

Әгәр озак авырган кеше инде тазарса, яисә карт кешегә уразасын тотарлык көч-хәл керсә, алар калдырган көннәре өчен уразаны каза итеп тотарга бурычлы. Әлеге очракта бирелгән фидияләре сәдака булып санала.

■ **«Ислам дине нигезләре» китабыннан**

# ТР мөфтие Дубайда танылган мөселман галимнәре белән очрашты



Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең Дубай шәһәрендә VIII Еллык инвестицион форум узды. Форумда Татарстан Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов җитәкчелегендәге республикабызның рәсми делегациясе составында Камил хәзрәт тә катнашты. Эш сәфәре кысаларында хәзрәт форумның рәсми ачылышында һәм пленар сессияләрдә дә булды. Моннан тыш, Дубайда булган чакта Татарстан мөфтиенең Форумда катнашучылар белән берничә эшлекле очрашулары планлаштырылган иде.

Мөфти үзенең эшлекле сәфәре барышында Шәех Мәэмүн Әр-Рави белән күреште. Галим мөфтинең Дубайга килүе хөрмәтенә аны кичке ашка чакырды һәм танылган мөселман галимнәре катнашында махсус мәҗлес уздырды.

Шәех Мәэмүн Әр-Рави – Гыйрак дин галиме, аның нәселе турыдан-туры Мөхәммәд пәйгамбәргә (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) тоташа. Шәех Дубайда яши, ул Коръәнне яттан белү буенча иң югары дәрәҗәгә ирешкән. Шәех Мәэмүн Әр-Рави Фарсы култыгы илләрендә Коръән конкурсларында баш хөкемдар һәм жюри рәисе булып тора, Әмирлек хакименең Коръән буенча Комитетында рәислек итә.

Камил хәзрәт шәехне Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Коръән-хафизләр мәктәбен торгызу юнәлешендәге эшчәнлеге һәм чаралары белән таныштырды: Коръән укучылар конкурслары, татар һәм рус телләренә тәфсирләр әзерләү, Коръәннәр бастыру һәм башкалар. Шәех үз чиратында Дубайда әлеге юнәлештә эшләрне оештыру буенча шәхси тәҗрибәсе белән уртаклашты.

■ dumrt.ru

# Казан имамнары Мәрҗани рухына дога кылды

18 нче апрель көнне бөек татар галиме һәм дин эшлеклесе Шиһабетдин Мәрҗанинең вафатына 129 ел тулды. Шул уңайдан Казан имамнары Мәрҗани мәчетенә Коръән ашына җыелды. Күренекле дин эшлеклесе нәкъ менә шушы мәчеттә имамлык итә, гомерен белем бирүгә, мәгърифәтчелек эшчәнлегенә багышлый. Әлеге чарада Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Мәрҗанинең бөек мирасын билгеләп, аның хезмәтләрен хәзерге вакытта Диния нәзарәте тарафыннан әзерләнә торган Нигезләмәләр әзерләгәндә куллану турында әйтте.



Мөфти хәзрәт Мәрҗанинең «Әл-баркул вәмииду галәл бәгыйдил мүсәммәә бин-нәкыйдый» китабының бик файдалы хезмәт булуы турында ассызыклап, имамнарның гыйбадәт кылулар турындагы Нигезләмәсен тулыландыру өстендә эш алып барылганда аның кыйммәтле чыганак булуын җиткерде: «Әлеге китапның башында Мәрҗани ни рәвешле фәтва бирелүе турында сөйли. Биредә шулай ук намазга кагылышлы мәсьәләләр, җомга үткәрү, тәсбих тарту тәртибе язылган. Кызыклы мәгълүматлар да урын алган: ашый башлаганда тоз татып карау, мисал өчен. Ул бидгатьме, юкмы? Моңа карата да ул үз фикерен белдерә», – дип сөйләде Камил хәзрәт Сәмигуллин. Мөфти шулай ук Мәрҗанинең барлык ислам фәннәре буенча китаплары булуы турында белдерде: Рәсму Усмани, игътикад, усулу тәфсир, кыскача гакыйдә, тарих китаплары... Хәтта аның әтисе Бәһаветдин Мәрҗанинең гарәп телендә тәфсире барлыгын белә без, дип, халкыбызның өйрәнеләсе мирасы искиткеч бай булуы турында сөйләде.

Камил хәзрәт Сәмигуллин Мәрҗанинең Бохарада булган чакта тәсаувыф гыйлеме белән шөгыльләнүен, аның Нияз Фарук Әл-Һинди янына йөреп, шәехнең дәресләрендә катнашып, аннан иҗазәт алып ишан дәрәҗәсенә күтәрелүен мисал итеп китерде. Мәрҗанинең хезмәтләре бөтен дөньяда билгеле булуын ассызыклап: «Мәрҗани – тарихчы, зур галим, ишан һәм көрәшче ул», – дип төгәлләде сүзен мөфти. Мәрҗани тарафыннан утыздан артык хезмәт язылa, бары шуның берсе генә татар телендә. Моның ни өчен шулай булуын да Татарстан мөфтие яхшылап аңлатып үтте.

Шиһабетдин Мәрҗанинең вафатына 129 ел тулуга багышланган мәҗлестә Казан шәһәре «Шамил» мәчете имам-хатыйбы Мәхмүд хәзрәт Шәрәфетдин, «Мәрҗани» балалар үзәгенә йөрүче балалар Коръән аятьләре укыды, Казанның аксакал хәзрәтләре дога кылды.

■ dumrt.ru

# Тәкъдир: иреклек яки мәҗбүрилек?



Казанның Галиев мәчетендә мөселман дискуссион клубының утырышлары дәвам итә. Апрель аенда узган утырышларның берсе яшьләр өчен аеруча әһәмиятле һәм күп сораулар тудыра торган: «Тәкъдир: иреклек яки мәҗбүрилек?» дигән темага багышланды.

Тәкъдир мәсьәләсен күпчелек аңлап бетерми яки гомумән дә аңламый, ә ул иманның бер нигезе (баганасы) булып тора, ягъни без тәкъдирнең яхшысы да, яманы да Аллаһы Тәгаләдән булуына иман китерергә тиешбез.

Дискуссион клубның махсус кунагы Коръән-хафиз Булат хәзрәт Мөбарәков иде. Ул тәкъдир төшенчәсенә түбәндәгечә билгеләмә бирде:

«Тәкъдир – ул алдан билгеләү. Аллаһы Тәгалә һәрберебезгә безнең белән булачак вакыйгаларны, ягъни маҗараларны билгеләгән. Аллаһы Тәгалә фикерләгән һәрнәрсә тормышка ашачак».

Исламда тәкъдир мәсьәләсен дөрес аңламаган ике төркем бар:

Беренчесе – кадәрия. Әлеге төркем вәкилләре тәкъдирне бөтенләй танымый һәм аны юк дип саныйлар.

Икенче төркем – җәбәрия. Бу юнәлеш тарафдарлары: «Аллаһы Тәгалә һәрнәрсәне билгеләгән һәм аны үзгәртеп булмый. Бөтен гамәлләребез Аллаһ кушуы буенча кылына, хәтта гөнаһлы эшләр дә», – дип саныйлар.

Адәм баласы кылган һәр гамәл Аллаһы Тәгалә теләге белән тормышка аша һәм кешенең һәр хәрәкәтен Аллаһ яраткан. Әмма сайлау хокукының бер өлешен Аллаһы Тәгалә инсаннарга биргән. Бу күренеш кешеләрдә аңлашыл-маучылык тудыра: «Ничек инде адәм баласы үз тормышын үзгәртә ала?»

Бу төшенчәне Булат хәзрәт болай аңлата: «Аллаһы Тәгалә һәр кешегә ният бирә, шушы ниятне кулланып, ул үз тәкъдирен үзгәртә ала». Аллаһы Тәгалә кешенең гамәлләрен, кеше аны башкарырга ният кылганнан соң һәм ниятләгәнен башкарырга тәвәккәл иткәннән соң гына барлыкка китерә.

Кайбер очракларда, кеше ничек тырышса да, уйланылган эш берничек тә барып чыкмый. Кешенең моңа кәефе кырыла, ул борчыла. Моны хәерлесе дип кабул итәргә кирәк, чөнки бары тик Аллаһы Тәгалә генә безгә нәрсә һәм кайчан хәерле булуын белә.

Хәзерге заман кешеләре һәр килгән сынауны уфтану белән каршы алалар, ә сәхабәләр вакытында кешеләргә өч көннән артык сынау килмәсә, алар кайгырганнар. Сынауларны Аллаһы Тәгалә үлем, Кыямәт көне, гамәлләребез өчен җавап бирү турында искә төшерер өчен бирә. Шуңа күрә килгән сынауларны рәхмәт белән кабул итеп, сабырлык кылу дөрес була.

Кеше гамәлләрен башкарган вакытта аларны Аллаһның боерыкларына туры китереп эшләсә, яхшылык эшләгән һәм изге юлда йөргән була. Әгәр аларны Аллаһның боерыкларына каршы эшләсә, начарлык эшләгән һәм яман юлда йөргән була. Шул сәбәпле, бу гамәлләр өчен Кыямәт көнендә хисап була һәм аңа савап яки гөнаһ языла, чөнки аларның барысын да ул үз ихтыяры белән эшли, беркем дә аны мәҗбүр итми.

Язмабызны йомгаклап шуны әйтәсе килә, тәкъдир мәсьәләләре кешене изгелек кылырга һәм начарлыктан тыелырга өнди. Кеше Аллаһы Тәгаләнең күзәтеп торганын һәм аны ахырдан хисап көтүен белә. Аллаһы Тәгалә аңа бер эшне эшләү яки эшләмәү ихтыярын бирде. Әгәр кеше бу ихтыярны изгелеккә эшләтмәсә, аңа бәхетсезлек һәм каты газап булыр. Шуның өчен тәкъдир хакыйкатен белгән, Аллаһы Тәгалә биргән акыл һәм ихтыяр нигъмәтен аңлаган чын мөэминнең һәрвакыт Аллаһтан куркуда булуын күрәбез. Ул Аның боерыкларын үти һәм Аның тыйганнарыннан тыела, Аллаһы Тәгаләнең газабыннан курка һәм Аның Җәннәтен өмет итә һәм иң кыйммәтле нәрсәгә ирешергә тырыша. Ул кыйммәтле нәрсә – Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы.

■ **Айгөл Минһаҗева, РИИ студенты**

# Дин турында уен аша



Апрель аенда Саба районының Иләбәр һәм Шәмәрдән авылларында балалар өчен квест уены оештырылды.

Уенны Казан һәм Саба мөселман яшьләре үткәрде. Уен Ислам диненә кагылышлы булган биремнәрдән гыйбарәт иде. Ул бик мавыктыргыч һәм күңелле узды, балалар да уеннан канәгать калдылар. Оештыручыларның максаты – балаларга мәгълүматны нәкъ менә шушындый форматта җиткерү иде, чөнки бүгенге көндә яшьләр китап укуга караганда, мәгълүматны күбрәк цифрлы форматта кабул итүне кулайрак күрә. Уенда дини гаиләдә тәрбияләнүче балалар белән беррәттән, әлегә диндә булмаган гаиләләрдәге балалар да катнашты. Бу үз чиратында алар өчен дә бер этәргеч. Күп вакытта кайберәүләр балаларны мәчеткә алып керүне хупламыйлар, тавышланалар дип зарланалар. Балаларда без кече яшьтән үк мәчеткә, дингә карата мәхәббәт уятмасак,15-20 яшьтән соң аларга дөрес юл күрсәтү көтелгән нәтиҗәләргә китерер идеме икән? Балалар бит безнең киләчәгебез, таянычыбыз. Алар динле, әхлаклы булсалар, димәк, җәмгыятебез дә сау-сәламәт булачак. Ислам диненең күркәмлеген, югары әхлаклылыкны без һәр яшь мөселманга җиткерергә тиешбез. Бу безнең бурыч.

Әнә шундый максатларны күз алдында тотып оештырылган иде бу уен. Үткәрелгән чарадан барысы да канәгать калдылар, дип ышанасы килә. Аллаһы Тәгалә һәрберебездән разый булып, әлеге гамәлләребезне дәвамлы кылса иде!

■ **Алмаз Галимҗанов, Саба районы имам-мөхтәсибенең яшьләр эшләре буенча ярдәмчесе**

# Һәркем Коръән-хафиз була ала



Изге Рамазан аен без Коръән ае дип атыйбыз. Раббабыз Изге Китабында болай дип хәбәр итә:

**«Рамазан ае бик шәрифле ай, ул айда Аллаһтан кешеләргә туры юлны күрсәтүче Коръән иңдерелде».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:185

Аллаһның илчесе (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын), сәхабәләр һәм алардан соң килгән мөселманнар да Рамазан аеның кичләрен Коръән укып үткәрергә тырыша иделәр. Бохари һәм Мөслим хәдисләр җыентыкларында Ибне Габбастан килгән хәдис бар: «Җәбраил фәрештә Расүлебез (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) белән Рамазанның һәр төнендә очрашып, аның белән Коръән өйрәнгән».

Уйлап кына карагыз: әгәр сез көндезләрен уразада булып, кичләрен Коръән укып үткәрәсез икән, Кыямәт көнендә сезгә истигъфар, ут газабыннан котылуны сорап торачак ике яклаучыгыз булыр – ул ураза һәм Коръән.

## Кем ул хафиз?

Коръәнне яттан белүчеләрне «хафиз» дип атыйлар. Аллаһ Китабын ятлау иң изге һәм саваплы гамәлләрдән санала. Әлбәттә, һәр мөселман бу күркәм дәрәҗәгә ирешергә, Аллаһы Тәгалә Сүзен саклаучы булырга тели, әмма еш кына безне курку, төрле мәшәкатьләр туктатып кала. Бу кыенлыкларны җиңәргә юл табар өчен Коръән-хафиз, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинның *«Һәркем Коръән-хафиз була ала»* китабына мөрәҗәгать итеп, аннан киңәшләр җыйдык.

Беренчедән, куркуыгызны җиңегез! Коръәнне ятлаган һәм аны саклаучы булып торучы кешеләрдән дә яхшырак кешеләр юк. Әлхәмдүлилләһ, гасырлар дәвамында хафиз булу дәрәҗәсенә бик күпләр лаек булган, һәм һәр мөэминнең күңелендә моңа ирешү өмете яши. Коръәннең җиңел ятлануы – бу китапның бер могҗизасы. Һәркем Коръән-хафиз була ала! Бу без уйлаганча кыен түгел, бары берничә киңәшне генә истә тотарга кирәк.

## Безнең төп дошманыбыз

Дошманыбыз шайтан турында онытырга ярамый. Шиксез, ул кешеләр арасында Аллаһы Тәгаләнең Китабын яттан белүчеләрнең булуын бик теләми. Иблис бар кешеләрне җәһәннәмгә кертергә вәгъдә итте.

Әйе, Иблис безнең төп дошманыбыз, ул бездән күпкә хәйләкәррәк. Уку вакытында ул безне: «Син файдасыз эш белән шөгыльләнәсең, син булдыра алмаячаксың…» – дип куркытып тора. Әмма тәкъвалык һәм ихласлылык бу вәсвәсәдән коткара, дәвалый.

## Беренче адымнар

Беренче чиратта Изге Китапны дөрес итеп укырга өйрәнергә, ягъни тәҗвидне үзләштерергә кирәк. Кеше дөрес һәм тиз итеп бер битне укый ала икән, ул Коръәнне ятлауга күчә ала. Тиз, йөгерек уку – ул авыр текстлы битне 1,5 минутта, җиңел битләрне 1 минут эчендә укып чыга алу. Әмма Коръәнне йөгерек укый алмаучыларга шунда ук ятлауга күчәргә киңәш ителми, чөнки ул зур кыенлыкларга очрый ала. Мондый шәкертләр күпчелек очракта Китапны ахырынача ятлап бетерми.

Үзенең хәтер үзенчәлекләреннән чыгып, һәркем үзенә туры килгән ятлау ысулын сайлап алырга тиеш. Мисал өчен:

– бер битне берничә тапкыр башыннан ахырынача укып ятларга;

– бер аятьне ятларга, аннан соң икенчесен, аннан соң бу ике аятьне бергә кушарга, аннан соң өченчесен ятларга һәм шулай дәвам итәргә;

– сүзләр буенча ятлау, ягъни башта бер сүзне ятларга, аннан икенчесен, аннан аларны тоташтырырга һәм аятьнең ахырынача шулай ятларга;

– битне өч яки дүрт өлешкә бүләргә, һәрберсен аерым ятларга, аннан соң тоташтырырга;

– битне астан ятлый башларга, ягъни иң астагы аятьтән ятлый башлап, бер-берсенә тоташтырып барып, иң өстәге аятькә җиткәнче ятларга;

– язып ятларга;

– тыңлап ятларга.

## Ятлаганнарны ныгытабыз

Ятлау ысулын шәкерткә хафиз остазы сайласа яхшырак булыр. Максатка ирешер өчен, укытучының даими рәвештә тикшереп торуы кирәк. Әгәр сез беренче ысулны сайларга, ягъни бер битне берничә тапкыр башыннан ахырынача укып ятларга, булсагыз, бер битне йөз, йөз илле тапкыр укып чыгарга кирәк. Күбрәк мәртәбә укыган саен – сез бу битне яхшырак беләчәксез.

Битне ятлаганнан соң, аны яттан дөп-дөрес итеп һәм әкренләп, һәр авазны дөрес әйтеп укый алсагыз, димәк, сез аны ятлагансыз, мондый ятлау тиз онытылмаячак һәм сез дәвам итә аласыз.

Хәтерем начар дип борчылырга кирәкми. Күпчелек ятлаучыларның хәтере Коръәннең дүрттән бер өлешен ятлагач кына ачылып китә. Шулай ук ятлаган аятьләрне шунда ук сөйли алмасагыз, борчылмагыз, чөнки ятлаган әйбер хәтердә калсын өчен, гадәттә бер төн яки ике көн үтүе таләп ителә.

## Хәтерне ничек яхшыртырга?

Хәтерне яхшыртыр өчен берничә кагыйдә һәм киңәш бар, алар теләсә-кайсы фәндә файдалы булыр:

– дәресне үзләштергәндә тырышлык кую;

– дәвамлылык;

– әзрәк ашау;

– тәһәҗҗүд намазларны калдырмау;

– Изге Коръәнне уку;

– китапларны укый башлаганда «бисмилләһ»тән башлау;

– дәресләрдән соң һәм намазлардан соң махсус дога кылу;

– сөекле Пәйгамбәребезгә салаватлар әйтү;

– гөнаһлардан саклану;

– мисвәк куллану;

– балдан ясалган ширбәт эчү;

– баллы әйберләр ашау;

## Коръән уку әдәпләре

1. Коръәнне укучы тәһарәтле булырга тиеш. Шулай ук аның киемнәренең чиста булуы, мисвәк һәм исле майлар куллану хуплана.

2. Коръән укыганда кыйбла тарафына юнәлеп утырырга кирәк.

3. «Әт-тәхият»не укыганда утырган рәвешле утырырга киңәш ителә.

4. Укыганнар турында фикер йөртеп, еларга тырышырга.

5. Китапны ашыкмыйча, кычкырып укырга. Әмма башкалар күрсен яки ишетсен өчен уку куркынычлыгы булса, яки башкаларга уңайсызлыклар тудырсагыз, кычкырып укырга кирәкми.

6. Матур итеп, көйләп укырга тырышырга.

**Рәмзилә Шафикова әзерләде**

# Сәхәр һәм ифтар әдәпләре

## Сәхәр ашауның фазыйләтләре

Рамазан аенда сөннәт булып ике ашау вакыты – сәхәр һәм ифтар тора. Әмма аларга гади иртәнге һәм кичке аш кебек кенә түгел, Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылу дип карарга кирәк. Аларны дөрес оештыру ураза тотуны бик күпкә җиңеләйтә.

Кемдер тәравих намазын укып кайтканнан соң, сәхәргә кадәр ятып тормый, Коръән укып, аның вакытын көтә. Сәхәргә тормас өчен кичтән үк ашап ятучылар да бар. Әмма ничек кенә булмасын, һәрбер мөселманга төннең соңгы өлешләрендә уразага керү нияте белән сәхәр ашау хәерле. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын): «Сәхәр ашагыз, дөреслектә ,иртәнге ризыкта бәрәкәт бар», – дип әйткән (Имам Бохари һәм Мөслим җыентыкларыннан). Шулай ук ул сәхәр вакытының өстенлеге турында: «Сәхәр ашаучы кешене Аллаһы Тәгалә һәм Аның фәрештәләре сәламләр», – дип әйтә (Имам Әхмәд).

Имам Әхмәд хәдисләр китабында сәхәргә карата мондый хәдис китерелә: «Бер йотым су белән булса да сәхәр кылыгыз». Бу хәдис исә Пәйгамбәребезнең сәхәр ашауның мөһимлегенә басым ясавы турында сөйли. Икенче бер хәдисендә Мөхәммәд Мостафа (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) болай дип әйтә: «Иртәнге ризыкта (сәхәрдә) бәрәкәт бар, шуңа күрә аны калдырмагыз».

## Сәхәр вакытында нинди ризыкка өстенлек бирергә?

Быел ураза яз һәм җәй айларына туры килә. Бигрәк тә эштә булган кешеләргә ураза вакытында хәлсезләнмәс өчен сәхәр ашау кирәк, чөнки эштә булган кешеләрнең хәл алырга вакытлары, гадәттә, күп булмый. Шуңа күрә сәхәрдә эчәсен китерми торган ризыклар белән, шулай ук углеводларга бай булган ризыклар: ярмалар, кара икмәк, яшелчәләрдән ясалган салат белән тукланырга киңәш ителә. Ашказанында углеводлар озак таркалганга күрә, алар кешене озак вакыт энергия белән тәэмин итеп торачаклар. Иртән кофе һәм чәй эчәргә яратучыларга Рамазан аенда аларны азрак куллану хәерлерәк булыр. Кара чәйне яшелгә алыштыру яисә сөт ризыкларына игътибарны арттырырга кирәк. Шулай ук сәхәр өчен хөрмә җимеше (финик) бик файдалы. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын): «Мөэминнең иң камил сәхәре – хөрмә беләндер», дип әйтте.

## Сәхәрнең сәламәтлек өчен файдасы

Сәхәр көннең беренче яртысында организм өчен көч бирә, ә икенче яртысында углеводлар таркалып, аны тукландырып торачак. Шуңа күрә матдәләр алмашына берниндә дә зыян килмәячәк.

## Ифтар кылуның әһәмияте

Җәбир (Аллаһ аннан разый булсын): «Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) болай дип әйткән: «Дөреслектә, Аллаһы Тәгаләнең ифтар вакытында уттан азат ителүче коллары бар һәм бу һәр ифтар вакытында була», – дип әйтте (Ибне Мәҗәһ). Шулай ук имам Әхмәд хәдисләр җыентыгында мондый хәдис китерелә: «Һәр ифтар вакытында Аллаһ уттан азат ителүчеләрне сайлый».

## Ифтар кылуны ашыктыру

Ахшам намазын укыганчы, кояш баегач ук авыз ачу хәерле. Аллаһның илчесе (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын): «Кешеләр ифтар кылуда ашыккан вакытта бәрәкәт килүдән туктамас», – дип әйткән (Имам Бохари һәм Мөслим).

## Нәрсә белән ифтар кылырга?




Гадәттә су һәм хөрмә белән авыз ачу каралган, чөнки Әбү Давыд, Әт-Тирмизи һәм Ибне Мәҗәһ хәдисләр җыентыгында мондый хәдис китерелә: Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын): «Ифтарны хөрмә белән кылыгыз, аны тапмасагыз, су белән, дөреслектә, ул сезне пакьләндерә», – дип әйткән.

Шулай итеп, ахшам намазы вакыты кергәч, сөннәт буенча шул көн уразасын тәмамлап, хөрмә яки су белән авыз ачыла. Авыз ачу ахшам намазына азан әйткәндә башкарыла. Ифтарның икенче өлеше, ягъни гаилә, дуслар белән җыелып, өстәл артына утырып ашау, намаздан соң була. Әнәс бине Мәлик (Аллаһ аннан разый булсын): «Минем Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) су белән булса да авыз ачмыйча, беркайчан да ахшам намазын укыганын күргәнем булмады», – дип әйткән.

## Ураза тотучының ике шатлыгы булыр

Кеше нәрсәне дә булса озак вакыт күрми торса, очрашу сәгате якынаю белән, шатлык хисе дә арта бара. Шуның кебек авыз ачу вакыты якынлашкан саен, мөэмин-мөселманның да уразаны исән-сау тотып чыга алганы өчен, Рамазанның тагын бер көнен гыйбадәттә үткәрә алганы өчен шатлык хисләре арта бара. «Ураза тотучының ике шатлыгы булыр: ифтар (авыз ачканда) шатлыгы һәм Аллаһы Тәгалә белән очрашу шатлыгы. Ураза тоткан кешенең авызыннан чыккан исне Аллаһ мускус (исле май) исеннән дә хушрак дип табар» (Имам Бохари).

Икенче шатлык: ураза тоту Җәннәткә керүгә сәбәп була. Мөхәммәд пәйгамбәр (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын): «Хактыр ки, Җәннәтнең «Әр-Райян» дигән капкасы бар. Кыямәт көнендә бу капкадан ураза тотучылар керәчәк. Һәм әлеге капкадан алардан башка беркем дә кермәячәк. Әйтелер: «Ураза тотканнар кайда?» Һәм алар калкачак. Һәм әлеге капкадан алардан башка беркем дә кермәячәк. Алар анда кергәч, бу капка ябылачак һәм инде башка беркем аның аша кермәячәк», – дип әйткән.

## Аллаһы Тәгалә ураза тотучының догасын кабул итә

Шул сәбәптән, ураза тоткан мөселман күп таптыр Аллаһтан үзе өчен дөньяда һәм ахирәттә бәхет һәм котылу, Ислам һәм мөселманнар өчен күп яхшылыклар сорарга тиеш була. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын): «Өч төрле кешенең догасы кире кагылмас: гадел җитәкченең, авыз ачканга кадәр ураза тотучының, һәм золым күрүченең», – дип әйткән. Тагын бер хәдистә: «Ураза тотучының ифтар вакытындагы догасы һич тә кире кагылмас», – дип әйтелгән.

## Ураза тотарга ниятләгәндә укыла торган дога

نَوَيْتُ اَنْ اَصُومَ صَوْمَ شَهْرِ رَمَضَانَ مِنَ الْفَجْرِ اِلَى
الْمَغْرِبِ خَالِصًا لِلَّهِ تَعَالَى

«Нәвәйтү əн әсуумә саумә шәһри Рамадаанә минәл фәҗри иләл мәгъриби. Халисән лилләһи тәгалә».

Тәрҗемәсе: «Ихластан Аллаһы Тәгалә өчен ошбу көннең фарыз уразасын таң вакытыннан башлап, кояш батканга кадәр тотарга ният кылдым».

## Авыз ачканнан соң укыла торган дога

اللَّهُمَّ لَكَ صُمْتُ وَبِكَ آمَنْتُ وَعَلَيْكَ تَوَكَّلْتُ وَعَلَى
رِزْقِكَ اَفْطَرْتُ فَغْفِرْلِى يَا غَفَّارُ مَا قَدَّمْتُ وَمَا اَخَّرْتُ

«Әллаһүммә ләкә сумтү вә бикә әәмәнтү вә галәйкә тәвәккәлтү вә галә ризкыйкә әфтартү фәгъфирлии йәә гаффәәру мәә каддәмтү вә мәә әххартү».

Тәрҗемәсе: «Әй Аллаһым! Ошбу рузамны мин Синең өчен генә тоттым, вә мин Сиңа гына иман китердем, вә Сиңа тәвәккәл кылдым, вә Синең ризыгың белән авыз ачтым. Әй гөнаһларны ярлыкаучы Аллаһ! Инде минем әүвәлге гөнаһларымны да, соңгы гөнаһларымны да ярлыкагыл».

■ **Ленар Хамматов әзерләде**

# «Аның әхлагы – Коръән иде»



Раббыбыз «Нун» сүрәсенең 4 нче аятендә:

**«Дөреслектә, син (Мөхәммәд) күркәм холыклысың»,** – ди.

Кешенең дәрәҗәсен күтәргән, камиллеккә ирешергә мөмкинлек биргән һәм башка мәхлуклардан аерып торган нигез булып әхлак тора. Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) әхлакны кешенең табигый асылында булырга тиешле сыйфат дип санаган. Бер хәдистә: «Мин әхлакны камилләштерергә җибәрелдем», – диелә.

Ислам дине аеруча зур игътибар иткән нигезләрнең берсе булып әхлак һәм әдәп тора. Моны Пәйгамбәребез дә бик еш кабатлый. Мисалга мондый хәдис китерергә була: «Күркәм әхлаклы мөэминнең иманы камил. Арагыздан иң яхшыгыз – хатынына карата яхшы мөгамәләдә булганыгыз» (Әт-Тирмизи җыенты-гыннан).

Әхлак – кешенең әйләнә-тирәдәгеләр белән мөнәсәбәтләрендә чагыла торган гадәтләре. Гадәтләр уңай һәм начар булырга мөмкин.

Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына ирешү өчен начар гадәтләрдән арынырга һәм, изге гамәлләр кылып, әкренләп үзеңне Исламның югары әхлагына якынайтырга кирәк. Исламның максатларының берсе – югары әхлаклы кешеләр тәрбияләү. Сөекле Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын): «Мин сезгә әхлакны камилләштерергә җибәрелдем», – дип әйтә. «Минем өчен иң сөеклеләрегез һәм Кыямәт көнендә иң якыннарыгыз – күркәм әхлак ияләре» (Әт-Тирмизи җыентыгыннан).

## Кешенең әхлагын камилләштерүдә иман һәм гыйбадәтнең урыны

Мөселманнар Аллаһка аларның бар гамәлләре билгеле булуын, фәрештәләрнең аларны язып баруын беләләр. Шулай ук Кыямәт көнендә изге гамәлләребез өчен саваплар алачагыбыз, һәм Аллаһ ярлыкамаса, начарлары өчен җәза алачагыбыз мәгълүм.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтә:

**«Берәү тузан бөртеге хәтле генә яхшылык кылган булса, аның җәзасын күрер. Вә берәү тузан бөртеге хәтле гөнаһ эшләсә, аның җәзасын күрер».**

«Зүлзиләт / Җир селкенмәк», 99:7-8

Моны белә торып, мөселман гөнаһ кылмаска тырыша һәм игелек кылырга өнди. Ышанмаучы яки иманы зәгыйфь булган кеше Аллаһы Тәгалә каршында җаваплылык тоймый һәм төрле гөнаһлы гамәлләр башкара.

Гыйбадәт ихласлылыкны көчәйтә: биш вакыт намаз безне һәрдаим Галәмнәрне бар кылучы – Аллаһы Тәгаләне искә алырга өйрәтә, ураза күңелләрдә мәрхәмәтлелекне арттыра, кулларны хәрамнан, ә телне ялганнан саклый, зәкәт саранлыктан коткара һәм үзара ярдәмләшү хисен ныгыта. Боларның барысы да җәмгыятькә файда китерә.

Гыйбадәт кылу фарыз булган кебек, әхлак кануннарын саклау да Аллаһы Тәгаләнең әмерләреннән. Асылда, Ислам диненең максаты булып кешеләрне начар гамәлләрдән ерагайту һәм аларда югары әхлак тәрбияләү тора.

## Әхлакның иң күркәм үрнәге

Пәйгамбәребез Мөхәммәд (аңа Аллаһның сәламе һәм рәхмәте булсын) – Аллаһы Тәгаләнең ихтыяры белән югары дәрәҗәдәге әхлакка һәм күркәм кешелек сыйфатларына ия булган кеше. Бервакыт Гайшәдән (Аллаһ аннан разый булсын) Мөхәммәд (аңа Аллаһның сәламе һәм рәхмәте булсын) турында сорагач: «Аның әхлагы – Коръән иде», – дип әйтә. («Шәрхуш-шифа. Галиййуль-Кари», I том, 222 б.)

Мөхәммәд (аңа Аллаһның сәламе һәм рәхмәте булсын) әхлак кануннарына таянып яшәгән һәм үзенең сәхабәләрен дә шуңа өйрәткән. Коръән Кәримдә әйтелә:

**«Дөреслектә, Аллаһның Расүлендә сез иярергә тиешле булган күркәм холык вә яхшы сыйфатлар бардыр, Аллаһтан савапны һәм ахирәттә җәннәтне өмет иткән хәлдә Аллаһны күп зикер итүче мөэминнәр өчен».**

«Әхзаб / Гаскәрләр», 33:21

Бу аять белән Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (аңа Аллаһның сәламе һәм рәхмәте булсын) яшәү рәвеше безнең Ислам кануннарына нигезләнгән тормышыбызның үрнәге булырга тиешлеген әйтә.

## Үз әхлагыңны ничек үзгәртергә һәм бу мөмкинме?

Бу дөньяга бала саф һәм гөнаһсыз хәлдә туа. Әгәр әтиәнисе аңа күркәм тәрбия бирсә, ул югары әхлаклы кеше булып үсәчәк, ә инде мондый тәрбия алмаганда, мондый кешедән әхлаклылыкны һәм кешелеклелекне көтүе авыр.

Авырудан савыгу өчен без тәнебезне төрле дарулар ярдәмендә дәвалыйбыз. Шулай ук без күңелебезне дә начарлыктан чистартып, камилләштерәбез.

Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның сәламе һәм рәхмәте булсын) әйткән: «Әхлагыгызны камилләштерегез». Аның бу сүзләре кешенең хасиятләре үзгәрә ала дигәнне раслый.

Әхлаксыз кеше белән аралашып, кеше тора-бара аның кимчелекләрен үзенә ала. Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның сәламе һәм рәхмәте булсын) болай дип әйткән: «Гадел һәм гөнаһлы кеше белән булган дуслык мускус сатучы һәм тимерче арасындагы дуслыкка охшаш. Беренчесеннән син йә мускусны сатып ала аласың, йә аның хуш исен тоярсың. Икенчесе янында очкыннар киемеңне яндырып алса, син аның начар исен сизәрсең» (Мөслим җыентыгыннан).

Әхлаклылык намуслы кешеләр белән аралашу юлы белән тәрбияләнә. Халык телендә: «Начар үрнәк йогышлы», – дип юкка гына әйтелмидер. Шуңа да кешенең әхлакка карата карашлары тотрыклы түгел икән, аңа әхлак сыйфатлары булмаган кешеләр белән аралашудан читләшергә кирәк.

Безнең максат – яхшы кешеләр белән дус булып, начар холыклылардан читләшү. Алар белән якынайсак та, бары тик аңа яхшы якка үзгәререргә ярдәм итү максатыннан гына аралашу.

Безнең тирә-ягыбыздагы мәгълүмати мәйданда да әхлаклылыкның мөһимлеген күрәбез. Без нинди музыка тыңлыйбыз, нинди фильмнар карыйбыз – болар барысы да мөһим. Киемнәребезнең эстетикасы да мөһим, ул нигезендә әхлак гадәтләре яткан безнең этикабыз белән каршылыкка керергә тиеш түгел.

## Әбү Хәнифәнең әхлак үрнәге

Имам Әбү Хәнифә (аңа Аллаһының рәхмәте булсын) – киңкырлы гыйлем, зирәк акыл һәм югары әхлакка ия булган күренекле ислам галимнәренең берсе. Ул үз үрнәгендә хакыйкатьне эзләүчеләрне дөрес юлга юнәлдерә.

Сәүдә эшләре белән шөгыльләнгәндә дә ул әхлакый принципларына каршы бармаган. Үзенә караганда күбрәк башкалар турында уйлаган.

Бервакыт бер хатын аңа ефәк күлмәген сатарга теләгән. Имам иң элек күпме күләмдә акча алырга теләвен сораган. Хатын: «Йөз дирһәм», – дип әйткән. Әбү Хәнифә каршы килеп: «Бу күлмәк йөз дирһәмнән артыграк тора. Аның бәясен әйтегез», – дигән.

Хатын хакын йөз тәңкәгә арттырган. Ләкин Әбү Хәнифә янәдән аның белән килешмәгән. Аның сүзләренә караганда күлмәк зур хакка ия булган.

Шулай итеп күлмәкнең бәясе 400 дирһәмгә кадәр җиткән. Имам барыбер үз сүзен куәтләгән. Хатын аны шаярта дип уйлаган, ләкин имам башка берәүдән күлмәкнең хакын белешергә кушкан. Бу хатын шулай эшләгән һәм күлмәкнең бәясе билгеле булган. Әбү Хәнифә аны 500 дирһәмгә сатып алган.

Бу үрнәге белән Әбү Хәнифә безгә башкаларның мәнфәгатьләрен дә онытмаска кирәклеген күрсәтә.

Мөселманнардагы күркәм әхлак һәм яхшы тәрбия Ислам динен таратуда иң яхшы ысуллардан була. Мисалга, Малайзия, Индонезия, Бруней Ислам динен гарәп диңгезчеләренең һәм сәүдәгәрләренең күркәм әхлакларына, гаделлекләренә карап кабул иткәннәр. Мөселманнарның әхлагы аерым шәхесләрнең һәм дә тулы бер халыкларның Ислам динен кабул итүләрендә мөһим урынны алып тора.

Аллаһы Тәгалә безнең гөнаһларыбызны гафу итсен, ярлыкасын һәм кешеләрдән иң күркәм булган Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (аңа Аллаһның сәламе һәм рәхмәте булсын) әхлагына һәм әдәбенә ияреге мөмкинлек бирсә иде. Әмин.

■ **Зәкәрия хәзрәт Тимганов, Комлы Кавәл бистәсе мәчетенең имам-хатыйбы**

# Әҗәтле үлмәсме?

Хөрмәтле редакция, үзебезне борчыган бер сорау белән мөрәҗәгать итәргә булдым әле. Безнең бер танышыбыз (аны хәзер дустыбыз дип әйтәсе килми инде) берничә ел элек бездән шактый зур суммада акча алып торды. Кайтарыр дип ышанып бирдек, ләкин килешенгән вакыт чыккач, ул башта «иртәгә»ләр, «киләсе атна»лар белән тынычландырып йөрсә, соңрак бөтенләй күзгә күренмәүне, качып йөрүне өстен күрде. Кыскасы, әҗәтне кайтарырга теләми. Динебездә бу мәсьәлә ничегрәк каралган икән?



Шәригать буенча кыен матди хәлгә тарыган кешегә әҗәткә акча биреп аның хәлен җиңеләйтү, булдыра алганча ярдәм итү саваплы гамәлләрдән санала. Әмма акча сорап мөрәҗәгать иткән кешенең мохтаҗлык дәрәҗәсен белү, шул акчаны ул нинди максатларга тотарга ниятләгәнен ачыклау да шарт булып тора. Әгәр кеше чыннан да ярдәмгә мохтаҗ икән, аңа әҗәткә бирү – сөннәт, ягъни саваплы гамәлдер. Әгәр өсте-өстенә әйбер алырга, ниндидер мөһим булмаган максатларга дип сорый икән, андый кешегә акча бирү мәкруһ (шелтәле гамәл), ә инде аракыга, отышлы уенга һ. б. шундый максатларга акча биреп тору – хәрам, ягъни тыелган гамәл булып санала.

Мөселман кешесенә әҗәткә алу рөхсәт ителсә дә, ул бу адымга бик мәҗбүр ителгән хәлдә генә барырга тиеш. Хәдисләрнең берсендә: «Бурычтан сакланыгыз! Дөрестән дә, бурыч ул – төннәрен кайгыру, көндезен исә кимсенү сәбәбедер». Нәрсә дә булса әҗәткә алганда, шул әҗәтне вакытында кайтаруны ныклап ниятләргә кирәк. Бу бик мөһим, чөнки әҗәтен кайтарырга ниятләгән кешегә Аллаһы Тәгалә Үзе ярдәм итә. Мөбарәк хәдисләрдән билгеле булганча, кире кайтару нияте белән алучыга Аллаһ ярдәм итә, ә кем кайтармау нияте белән алса, карак хөкемендә булыр һәм аны Аллаһы Тәгалә һәлак итәчәк... Әҗәтле булуын онытмыйча, моңа җаваплы карап борчылган кешегә Аллаһы Тәгалә хәтта махсус сак куя: саклаучы фәрештәләр бу кешене бәла-казалардан саклый, имин булуын кайгырта... Шуңа күрә халыкта «әҗәтле үлмәс» дигән әйтем дә йөридер.

Бурычка алу белән бәйле тагын берничә мәсьәләгә игътибар итәргә кирәктер. Әгәр кеше бурычка кергән икән, аның башкаларга сәдака бирергә, мал белән бәйле изгелек кылырга, мәсәлән, хаҗга барырга хакы юк. Әҗәтле кеше әҗәтен кайтаруны үзенең иң беренчел максаты итеп куярга тиеш. Галимнәр билгеләп үткәнчә, хәтта ашауда да бу кешегә артыклык күрсәтмәскә, әйтик, җиләк-җимешләрдән, башка кыйммәтле ризыклардан баш тартырга кирәк.

Дөрестән дә, бүген шактый кешене «кайда гына әҗәткә алыйм икән» дигән мәсьәлә борчый, ләкин «алынган акчаны ничек кайтарырмын?» дигән уй аларның башына килми һәм бу кешеләр «әйдә, ярар»га өметләнеп, йә танышбелешләреннән, йә банктан зур суммада акча алып торуны әллә ни зур проблема итеп күрми. Шунысы да бар: кайберәүләр әҗәтләрен чыннан да кайтара алмаганга кайтармый, әмма икенчеләре мөмкинлекләре була торып та, кеше акчасын кайтаруны мөһим эшкә санамый. Шундыйлар, әҗәтләре булуга карамастан, яңадан-яңа кием ала, машиналарын яңарта, фатирларында ремонт ясый, ягъни үз кирәгенә акча таба, ә әҗәтне кайтарырга – юк. Исләренә төшерә башласаң, шундыйлар әрсезләнеп, аралашудан баш тарта, шалтыратсаң телефонны сүндерә, килсәң – ишекне ачмый. Бу, әлбәттә, берничнди әдәп кысаларына сыймый. Мөселман галимнәре белдергәнчә, ислам дине буенча мондый кешеләр катгый шелтәләүгә лаек. Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) хәдисләренең берсендә бу хакта болай диелә: «Әгәр әҗәтен кайтарырга мөмкинлеге була торып та, әҗәтле кеше моны эшләмәсә, ул башкаларны кыерсытучы залим кебек булыр һәм аңа бу гөнаһка тиң җәза бирелер». Башкаларны шулай борчып, әҗәтен кайтармыйча йөргән кешегә Аллаһ ачу күзе белән карар һәм ул тормышындагы бәрәкәтен югалтыр. Мәгълүм мәкальдә «әҗәтле үлмәс» дип әйтелсә дә, чынлыкта беркем дә бу дөньяда мәңгегә калмый. Ә инде кеше бурычлы килеш бакыйлыкка күчә икән, ахирәттә, Кыямәт көнендә, Аллаһы Тәгалә аңа әйтер: «Кемнеңдер хакларын Мин шулай синең өстә калдырырмым дип уйладыңмы әллә?!» Шуннан соң бурычын кайтармаган кешенең барлык яхшы гамәлләрен теге акча биреп торган кешегә тапшырыр. Әгәр бурычлы килеш вафат булган кешенең яхшы гамәлләре булмаса, акча биреп торган кешенең гөнаһлары аңа язылап куелыр, ди...

Пәйгамбәребез Мөхәммәд (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) мөселманнарны эшләргә, кәсеп итәргә чакырып, матди авырлыкларны әҗәткә кермичә хәл итәргә тырышыгыз, дип өйрәтеп калдырды. Инде башка чара юк икән, әҗәткә алу мөмкин, әмма зур сумма турында сүз барганда, килешү төзеп, расписка язып әҗәткә бирергә яки бурычка акча сораучының ниндидер әйберсен яки документын залогка калдыруын сорарга кирәк. Мөселманнар нәтиҗәле кәсеп, бәрәкәтле тормыш теләп, Аллаһы Тәгаләдән: «Йә Раббым! Мине имансызлыктан һәм әҗәттән сакла...» – дип һәрдаим дога кылырга һәм ихлас иман белән чиста намуска таянып гамәл кылырга тиеш. Бу – безнең дөньядагы һәм ахирәттәге бәхетебезнең нигезе.

■ **Җавапны Кукмара мәдрәсәсе мөдире Ришат хәзрәт Курамшин әзерләде**

# Бурычлардан котылу өчен нинди дога укырга?

Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) йокларга ятканда укыган догаларының берсе:

اللَّهُمَّ رَبَّ السَّمَاوَاتِ وَرَبَّ الْاَرْضِ وَرَبَّ
الْعَرْشِ الْعَظِيمِ رَبَّنَا وَرَبَّ كُلِّ شَىْءٍ. فَالِقُ
الْحَبِّ وَالنَّوَى وَمُنْزِلَا التَّوْرَاةِ وَالْاِنْجِيلِ
وَالْفُرْقَانِ. أَعُوذُ بِكَ مِنْ شَرِّ كُلِّ شَىْءٍ
اَنْتَ اَخِذٌ بِنَاصِيَتِهِ. اللَّهُمَّ اَنْتَ الْاَوَّلُ
فَلَيْسَ قَبْلَكَ شَىْءٌ. وَاَنْتَ الْاَخِرُ فَلَيْسَ
بَعْدَكَ شَىْءٌ. وَأَنْتَ الظَاهِرُ فَلَيْسَ فَوْقَكَ
شَىْءٌ وَأَنْتَ الْبَاطِنُ فَلَيْسَ دُونَكَ شَيْءٌ
إِقْضِ عَنَّا الدَّيْنَ وَأَغْنِنَا مِنَ الْفَقْرِ

**Әллаһүммә раббәс-сәмәәүәәти вә раббәл-әрдый вә раббәл-гаршил-газыыйми раббәнәә вә раббә күлли шәй ин. Фәәликул-хәбби вәннәвә вә мүнзиләәт-тәүраати вәл-инҗиили вәл-фуркаан. Әгүүзү бикә мин шәрри күлли шәй ин әнтә әәхыйзүн бинәәсыйәтиһ. Әллаһүммә әнтәл-әүүәлү фәләйсә кабләкә шәй үн. Вә әнтәл-әәхыйру фәләйсә бәгъдәкә шәй үн. Вә әнтәз-зааһиру фәләйсә фәүкакә шәй үн, вә әнтәл-бәәтыйну фәләйсә дүүнәкә шәй үн. Икъдый гәннәд-дәйнә үә әгънинәә минәл-фәкъри.**

«Аллаһым! Әй, кукләрнең, җирнең һәм бөек тәхетнең Иясе! Әй, безнең Раббыбыз һәм бөтен нәрсәнең Раббысы! Әй, орлыкларны тишелдерүче һәм Тәүратны, Инҗилне һәм Коръәнне индерүче бөек Аллаһы! Һәр төрле начарлыклардан Сиңа сыенамын. Элек – Синсең. Синнән элек һичбер нәрсә юк иде. Соң – Синсең. Синнән соң да һичбер нәрсә булмаячак. Син ачыксың. Синнән өстен бернәрсә юк. Синнән бөек һичбер нәрсә юк. Әй Раббым! Безгә бурычларыбызны түләргә ярдәм ит һәм безне фәкыйрьлектән коткар» (Имам Мөслим хәдисләр җыентыгы).

■ **«Иң кирәкле догалар» китабыннан**

# Саранлыкның зыяны

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай ди:
**«Үзенең саранлыгыннан сакланган кешеләр уңышка ирешәчәкләр».**
«Тәгабүн / Алдану», 64:16

**«Аллаһы Тәгалә үзләренә нигъмәт итеп биргән нәрсәләргә саранланучылар моны үзләре өчен яхшы дип уйламасыннар. Киресенчә, бу алар өчен начар. Кыямәт көнендә саранланып җыйган маллары муеннарына чорналачак».**
«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:180

Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) болай дип әйткән:
***«Комсызлыктан сакланыгыз, чөнки сезгә кадәр яшәгән кешеләр комсызлык аркасында гына һәлак булдылар; комсызлык аларны саранлыкка этәрә иде, алар саранландылар; туганлык бәйләнешләрен өзәргә этәрә иде, алар – өзделәр; гөнаһ кылырга этәрә иде, алар – кылдылар»*** (Әбү Давыд).

Гали сөйләгән: «Кешеләр өчен шундый заман җитәр: бай кеше, гәрчә аңа бу боерылмаган булса да, үзендә булган нәрсәгә ябышып ятачак».

Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:
**«Бер-берегезгә яхшылык теләү турында онытмагыз».**
«Әл-Бәкара / Сыер», 2:237

Шәгъби: «Ике сыйфат: саранлык һәм ялганчылыкның кайсы озаграк вакыт җәһәннәм утында булачагын белмим», – дигән.

Пәйгамбәр (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) Бәнү Лихьян кабиләсе вәкилләреннән: «Сезнең җитәкчегез кем?» – дип сораган. Алар: «Җәдд ибне Кайс, ләкин ул саранлыгы белән аерылып тора», – дигәннәр. Шунда Пәйгамбәребез: «Саранлыктан да начарრак нинди авыру булырга мөмкин? Сезнең җитәкчегез Бишер ибне Бәрра ибне Мәгърур булсын», – дип әйткән (Тәбәрани).

Бишер болай дип әйткән: «Саранга карау йөрәкне явызландыра, ә аның белән очрашу мөэминнәрнең күңеленә кайгы булып ята».

Ибне Мөгаз: «Байлыгына карата иң күп саранланучы кеше башкаларга караганда үзенең намусы турында азрак уйлый», – дигән.

«Бер колның йөрәгендә бер үк вакытта саранлык та, иман да яши алмас» (Нәсаи).

«Муса (аңа Аллаһның сәламе булсын) өммәтеннән Карун исемле бер кеше бик бай, ләкин ифрат та саран була. Саранлыгының сәбәбен болай аңлата икән: «Мин бу байлыкка үз сәләтем һәм иҗтиһадым белән ия булдым, кемгә булса да аннан өлеш чыгарырга тиеш түгелмен».

Раббыбыз Коръән Кәримдә Карунның бу сүзләрен кешеләргә гыйбрәт булсын дип бирә. Шулай итеп, Ул: «Аң булыгыз, сез дә Карунга охшап кала күрмәгез», – дип инсаннарны кисәтә. Ягъни саранлык күрсәткән кеше Карунга охшар. Юмарт кеше исә Пәйгамбәребезнең сөннәтенә оеган (ияргән) булыр».

■ **«Шура» №20**

# Беренче тапкыр җомга намазы кайчан укылган?

Җомга намазының кайчан, кайда һәм кем тарафыннан беренче тапкыр кылынган булуы хакында төрле риваятьләр бар. Аларның кайберләрен китерик:

**1.** Пәйгамбәребез Мөхәммәд (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) Мәдинәгә күченгәнче җомга намазын кылырга рөхсәт бирә. Бу вакытта ул үзе Мәккәдә җомга намазы кыла алмый, ләкин Мусаб ибне Өмәйргә (Аллаһ аннан разый булсын) язылган хатында ул: «Яһүдләр шимбә саен ачык рәвештә Зәбурны укыйлар. Сез дә җомга көнне үз хатыннарыгызны һәм балаларыгызны җыеп, кояш зәвәлдән авышкач, Аллаһы Тәгаләгә ике рәкәгать намаз белән якынаегыз», – дип әйтә (Мөхәммәд Хәмидуллаһ, Вәсәикус-Сийәсиййә, 35 б.; Әлуси, Рухүл-Мәәни, XXVNI/99).

Ибне Садның «Тәбакат»ендә әлеге риваятьнең дәвамы китерелә: «... һәм алар унике кеше булып, Әсәд ибне Усамәнең йортында җомга намазын кылдылар». Бу риваятьтән чыгып, җомга намазы Мәккәдә фарыз кылынган, дип әйтергә була.


**2.** Габдрахман ибне Кәгъб болай дип әйткән: «Минем әтием күрү сәләтен югалткач, мин аны җомга намазына үзем алып бара башладым. Азан тавышын ишеткәч, ул Әбү Умәм Әсәд ибне Зөрар өчен дога кылды. Мин моның сәбәбен сорадым. Җавап итеп ул: «Әй углым! Ул Мәдинәдә, Бәнү Бәйәд кварталында безгә җомга намазы үткәргән беренче кеше иде», – дип әйтте. Мин тагын сорадым: «Сез ул көнне ничә кеше идегез?» Ул: «Без кырык кеше идек», – дип әйтте (Әлуси, Рухүл-Мәәни, XXVNI/99).

**3.** «Өмдәтуль-Кари» китабында алдагысын тулыландырып риваять китерелә: «Ибне Сирин сөйләгән: «Мәдинә мөселманнары Аллаһы илчесенең һиҗрәтенә һәм җомга намазына бәйле аять иңгәнчегә кадәр бергә җыелышалар. Нәкъ менә алар әлеге намазга мондый атама бирүчеләр булганнар. Алар: «Яһүдләр һәм христианнар атнаның билгеле бер көннәрендә бергәләшеп җыелалар. Әйдәгез, без дә билгеле бер көндә җыелып, Аллаһы Тәгаләне искә алып, намаз кылыйк», – дип әйтәләр. Моның өчен алар йәүмүл-әрубәне сайлыйлар һәм Әсад йортында җыела башлыйлар. Ул алар өчен ике рәкәгать намаз үткәрә. Бу җыелышта алар әлеге көнне «җомга» дип атарга карар кылалар. Шуннан соң Әсәд алар өчен сарык чала һәм аларны ашата, чөнки алар бик күп булмыйлар (Хәким, Әл-Мустәдрак, I/28I; Ибне Мәҗәһ, Сунан, I/344).

**4.** «Әл-Мәгариф» китабында риваять китерелә: «Зуһри сөйләгән: «Мусәб ибне Умәйр (Аллаһ аннан разый булсын) мәдинәлеләр янына, Коръән өйрәнергә җибәрелгәч, ул аларга җомга намазын үткәргән беренче кеше булган (анда әле Пәйгамбәр Мөхәммәд килгәнче)» (Хәший-әтус-Сәләби Әт-Тәбйинил-Хәкаик, I/217). Имам Әлуси санап үтелгән әлеге риваятьләрдән соң: «Бу сорауга бәйле риваятьләрнең иң ышанычлысы – Мәдинәдә беренче намазны Әсәд үткәргән дигәне», – дип әйтә.

**5.** Аллаһы Тәгаләнең илчесе тарафыннан үткәрелгән җомга намазына килгәндә, ул Мәдинәдән ерак булмаган Куба җирлегендә, Пәйгамбәр Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм һиҗрәт кылган вакытта була.

■ **islam-today.ru**



# Гайбәт кайсы очракларда рөхсәт ителә?

Сүз йөртү, гайбәт сөйләү, яла ягу, башкалар хакында начар сүзләр әйтү Ислам динендә олуг гөнаһ булып санала. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) сәхабәләреннән: «Сез гайбәтнең нәрсә икәнен беләсезме?» – дип сорый. Алар: «Аллаһ һәм Аның илчесе бу хакта яхшырак белүчеләр», – дип җавап бирәләр. Һәм Пәйгамбәр: «Әгәр бер кеше турында аның күңеленә хуш килми торган сүзләрне ул югында сөйлибез икән, ул гайбәт була», – дип аңлата. Сәхабәләр: «Йә Расүлуллаһ! Ә әгәр ул кимчелек кешедә чыннан да булса?» – дип әйтәләр. Аллаһның илчесе: «Әгәр ул кимчелек бу кешедә чыннан да булса, син ул югында аның артында гайбәт сөйләгән буласың, әгәр ул кимчелек бу кешедә булмаса, аңа яла яккан буласың», – дип әйтә.

Башка бер хәдистә: «Әгәр бер мөселман икенче мөселман хакында гайбәт сөйләгән вакытта, тыңлап торучы гайбәт сөйләнгән дин кардәшен якларга мөмкинлеге булып та, аны якламаса, Аллаһы Тәгалә аны бу дөньяда да, ахирәттә дә түбәнсетер», – дип әйтелә.

Шулай да алда санап кителәчәк 5 очракта шәригать гайбәт сөйләүне рөхсәт итә:

1. Кешегә золым кылынган вакытта: бер мөселман бер кешегә золым кылса, кыерсытса, түбәнсетсә, моны барып берәрсенә хәбәр итү дөрес, чөнки тиешле статусы булган кеше бу очракта золым кылынган кешегә ярдәм күрсәтә ала.

2. Гаделлек урнаштыру өчен. Дәрәҗәсе һәм көче булган кешегә, ул хәлне үзгәртә алсын өчен, ярдәм сорап мөрәҗәгать итү очрагында гайбәт сөйләү рөхсәт ителә. Мәсәлән: «Фәлән кеше фәлән явызлык кылды, чарасын күрегез», – дип әйтү. Бу вакытта сез гаделсезлеккә каршы көрәшкән буласыз.

3. Фәтва сораганда. Мәсәлән, мөфтигә сорау биргәндә: «Минем әти фәлән эш эшләде, ирем фәлән гамәл кылды, мин бу очракта нәрсә эшләргә тиеш?» – дип сөйләү рөхсәт ителә, чөнки моның мәсьәләне хәл итәргә ярдәм итүе мөмкин. Дин хезмәткәренә киңәш сорап мөрәҗәгать итү дөрес.

4. Кешеләрне кисәтү һәм аларны афәттән саклау өчен. Бер кеше башка бер кешеләргә зыян китерергә теләгәндә, ул кешене туктатып булмаган очракта, һәм бу зур афәткә китерәчәгe билгеле булганда, мөселман кешесенә шул кешенең золымы хакында хәбәр итү фарыз була.

5. Ачыктан-ачык ярамаган эш эшләүчене туктату өчен. Мәсәлән, берәр каракның әйбер урлавы хакында җәмгыятькә хәбәр итәргә кирәк. Кеше үзе үзгәртә ала торган кимчелекләр хакында кешенең шәхсән үзенә хәбәр ителә.

■ **islam-today.ru**

# Иртәнге намаздан соң үтәлә торган сөннәтләр

Көн никадәр иртәрәк башланса, шуның кадәр нәтиҗәлерәк булганын һәм ул көндә планлаштырылган эшләрнең күбесе үтәлгәнен күзәткәнегез бардыр. Ислам динендә иртәрәк тору, иртәнге сәгатьләргә аерым игътибар бирү сөннәт булып санала. Мөселман кешесе өчен бәрәкәтле вакытларның берсе – иртәнге намаздан соңгы вакыт. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын): «Йә, Аллаһ, иртәнге сәгатьләрдә минем өммәтемә рәхмәтеңне бир», – дип әйткән.

## 1. Аллаһы Тәгаләне зикер итү

Хәдисләрдә болай дип әйтелә: «Намазыннан соң шул ук урында калып, Аллаһны зикер итүчеләргә фәрештәләр Аллаһтан гафу сорап торырлар. Алар: «Йә, Аллаһ, аны ярлыка. Йә, Аллаһ, аңа рәхимле бул», – дип әйтәләр»(Имам Бохари).

Шулай ук икенче хәдистә: «Иртәнге намаздан соң үз урынында Аллаһны зикер итү өчен калып, шул урынында кояш чыкканчы торса һәм аннан соң ике рәкәгать намаз укыса, аңа камил рәвештә кылынган хаҗ һәм гомрә савабы язылачак», – дип әйтелә (Имам Мөслим).

## 2. Духа намазы

Духа намазының вакыты кояш чыкканнан соң намаз укыр өчен мәкруһ вакыт узгач башлана һәм кояш зәвәлгә якынлашуга, ягъни өйлә намазының вакыты керергә 20-40 минут кала, тәмамлана. Бу намаз көннең бәрәкәтле үтәчәгенә китерә торган гыйбадәтләрнең берсе.

Тирмизи риваятьләрендә: «Кем даими рәвештә 2 рәкәгать духа намазы укыса, аның (кече) гөнаһлары, диңгез күбеге кадәр күп булса да, кичерелер», – дигән хәдис китерелә.

Тәбәрани җыентыгында мондый хәдис китерелә: «Җәннәттә «Духа» исемле ишек бардыр. Кыямәт көнендә: «Дөньялыкта духа намазын укучы кешеләр кайда? Бу сезнең ишек, Аллаһның рәхмәте белән алардан үтегез», – дигән тавыш яңгырар».

## 3. Коръән уку

Иртәнге сәгатьләрне Коръән укуга һәм аның мәгънәләре турында уйлануга багышлау бик файдалы. Бу вакытта кеше Коръән белән ялгызы гына калып, бар дөньядан читләшә һәм шул сәбәпле Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына ирешә ала. Иртә – Коръән ятлар өчен иң кулай вакыт.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«Төш авышканнан алып төнгә кадәр намазларыгызны укыгыз! Таңда Коръәнне күбрәк укыгыз. Дөреслектә, иртән Коръән укучыларга фәрештәләр шаһит булыр!»**

«Бәни Исраил», 17:78

Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) бер хәдисендә: «Әгәр кеше Коръәнне кич җиткәч укып бетерсә, фәрештәләр таң атканчы аңа рәхмәт һәм бәрәкәт теләр. Әгәр ул таңда укып бетерсә, фәрештәләр кичкә кадәр аңа рәхмәт һәм бәрәкәт теләр», – дип әйтелә.

## 4. Дога кылу

Кешеләр үз вакытларын йокыга сарыф иткән чакта, бу бәрәкәтле сәгатьләрне Аллаһы Тәгаләгә дога кылу, үзең, туганнарың һәм дусларың өчен бәхет-сәгадәт сорау хәерле гамәлләрдән санала. Дога кылганда Аллаһтан гына өмет итеп, ихлас ният белән сорау тиешле.

## 5. Көн тәртибен төзү

Бу турыдан-туры Пәйгамбәребезнең сөннәтенә булмаса да, вакыт нигъмәтенә ихтирам белән карау була. Иртә белән үк үзегезнең көн дәвамында эшләячәк эш-гамәлләрегезне планлаштырып, язып куегыз. Бу көннең нәтиҗәле үтүенә тагын бер сәбәп.

■ **islam-today.ru**

# Бу өч кеше җәннәткә кермәячәк

Балалар әти-әнисенә буйсынырга, аларны тыңларга, ихтирам итәргә, аларга карата йомшак һәм рәхмәтле булырга тиешләр. Ана кеше аеруча зур хөрмәткә лаек булырга тиеш, чөнки бу ананың хакы. Ул йөкле вакытта бөтен авырту һәм авырлыкларны күтәрә, баласын имезә һәм тәрбияли.

Мөхәммәд пәйгамбәр (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын): «Җәннәткә өч төрле кеше кермәячәк: әти-әнисенә буйсынмаган кеше, зинада арадашчы булып йөргән кеше, ир-атка охшарга тырышкан хатынкыз», – дигән.

Балалар әти-әниләрен олыгайган көннәрендә кайгыртырга, карарга тиеш: **«Аллаһ фәкать Аңа гына гыйбадәт кылырга хөкем итте вә ата-анага изгелек кылырга әмер бирде. Әгәр син исән чакта аларның берсе яки икесе дә картлыкка ирешсәләр, син аларга «уф» та димә, тавыш күтәрмә, ә мөлаем сүзләр сөйлә! Вә аларга шәфкать итеп, рәхим канатларыңны җәй! «Ий Раббым, алар мине кечкенә чагымда мәрхәмәт белән үстергән кебек, Син дә аларга дөньяда һәм ахирәттә шәфкать кылчы!»** – дип әйт»

«Бәни Исраил», 17:23-24

Мөхәммәд пәйгамбәр (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын): «Иң куркыныч гөнаһны кеше әти-әнисен түбәнсеткәндә кыла», – дип әйткән. Мөселман моңа юл куярга тиеш түгел. Әмма Ислам дине ата-ана баласын диннән ерагайтырга тырышканда аларны тыңламаска һәм буйсынмаска рөхсәт итә: **«Әгәр ата-анаң сине дәлилең булмаган нәрсәне Миңа шәрик итүеңә көчләсәләр, син аларга итагать итмә».**

«Локман» 31:15

■ **islam-today.ru**




## «Ислам дине нигезләре» китабы

«Ислам дине нигезләре» китабы укучыларны Ислам диненең асылы белән таныштыру нияте белән әзерләнде. Аның эчтәлеге Гакыйдә, Фикһ, Ислам тарихы, Әхлак кебек мөһим бүлекләрдән гыйбарәт. Башлангыч дини белем вә тәрбия алырга, ягъни Ислам дине нигезләрен өйрәнергә теләүчеләрнең гозер-үтенечләрен исәпкә алып, китапта тәкъдим ителә торган темалар мөмкин кадәр гади, аңлаешлы итеп яктыртылды.

«Ислам дине нигезләре» дип атала торган әлеге хезмәт Ислам дине белән кызыксынучы киң катлау җәмәгатьчелек өчен файдалы булыр.

Әлеге китапны http://huzurshop.ru сайтыннан яки Казан шәһәре, Газовая урамы, 19 нчы йорт (РИИ бинасы) адресы буенча урнашкан кибеттән алырга мөмкин.

Телефон: +7 (843) 258-52-01

дин вә мәгыйшәт

«ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ» ГАЗЕТАСЫНА
2018 елның икенче яртысына язылу башланды

- Газета айга бер тапкыр чыга
- Ярты елга язылу бәясе: 132 сум
- Язылу индексы: П4333
- Түбәндәге сайтларда да язылу мөмкин:
  podpiska.pochta.ru һәм uslugi.tatarstan.ru сайтының «Подписка» бүлегендә.

Белешмәләр өчен телефон: 598 09 42




### КАЗАН ӨЧЕН МАЙ АЕНА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

| Көн | Иртәнге намаз | | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ясту намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | | | | | |
| 01.05.2018 | 00:44 | 02:30 | 04:00 | 12:00 | 16:52 | 19:21 | 21:45 |
| 02.05.2018 | 00:36 | 02:28 | 03:58 | 12:00 | 16:53 | 19:23 | 21:50 |
| 03.05.2018 | 00:26 | 02:26 | 03:56 | 12:00 | 16:54 | 19:25 | 21:54 |
| 04.05.2018 | 00:14 | 02:24 | 03:54 | 12:00 | 16:56 | 19:27 | 21:58 |
| 05.05.2018 | 23:56 | 02:22 | 03:52 | 12:00 | 16:57 | 19:29 | 20:59 |
| 06.05.2018 | 01:50 | 02:20 | 03:50 | 12:00 | 16:58 | 19:31 | 21:01 |
| 07.05.2018 | 01:47 | 02:17 | 03:47 | 12:00 | 16:59 | 19:33 | 21:03 |
| 08.05.2018 | 01:45 | 02:15 | 03:45 | 12:00 | 17:00 | 19:35 | 21:05 |
| 09.05.2018 | 01:43 | 02:13 | 03:43 | 12:00 | 17:01 | 19:37 | 21:07 |
| 10.05.2018 | 01:41 | 02:11 | 03:41 | 12:00 | 17:03 | 19:39 | 21:09 |
| 11.05.2018 | 01:39 | 02:09 | 03:39 | 12:00 | 17:04 | 19:41 | 21:11 |
| 12.05.2018 | 01:37 | 02:07 | 03:37 | 12:00 | 17:05 | 19:43 | 21:13 |
| 13.05.2018 | 01:35 | 02:05 | 03:35 | 12:00 | 17:06 | 19:45 | 21:15 |
| 14.05.2018 | 01:34 | 02:04 | 03:34 | 12:00 | 17:07 | 19:46 | 21:16 |
| 15.05.2018 | 01:32 | 02:02 | 03:32 | 12:00 | 17:08 | 19:48 | 21:18 |
| Изге Рамазан ае башлана | | | | | | | |
| 16.05.2018 | 01:30 | 02:00 | 03:30 | 12:00 | 17:09 | 19:50 | 21:20 |
| 17.05.2018 | 01:28 | 01:58 | 03:28 | 12:00 | 17:10 | 19:52 | 21:22 |
| 18.05.2018 | 01:26 | 01:56 | 03:26 | 12:00 | 17:11 | 19:54 | 21:24 |
| 19.05.2018 | 01:25 | 01:55 | 03:25 | 12:00 | 17:12 | 19:55 | 21:25 |
| 20.05.2018 | 01:23 | 01:53 | 03:23 | 12:00 | 17:13 | 19:57 | 21:27 |
| 21.05.2018 | 01:21 | 01:51 | 03:21 | 12:00 | 17:14 | 19:59 | 21:29 |
| 22.05.2018 | 01:20 | 01:50 | 03:20 | 12:00 | 17:15 | 20:01 | 21:31 |
| 23.05.2018 | 01:18 | 01:48 | 03:18 | 12:00 | 17:16 | 20:02 | 21:32 |
| 24.05.2018 | 01:17 | 01:47 | 03:17 | 12:00 | 17:17 | 20:04 | 21:34 |
| 25.05.2018 | 01:15 | 01:45 | 03:15 | 12:00 | 17:18 | 20:06 | 21:36 |
| 26.05.2018 | 01:14 | 01:44 | 03:14 | 12:00 | 17:19 | 20:07 | 21:37 |
| 27.05.2018 | 01:13 | 01:43 | 03:13 | 12:00 | 17:19 | 20:09 | 21:39 |
| 28.05.2018 | 01:11 | 01:41 | 03:11 | 12:00 | 17:20 | 20:10 | 21:40 |
| 29.05.2018 | 01:10 | 01:40 | 03:10 | 12:00 | 17:21 | 20:12 | 21:42 |
| 30.05.2018 | 01:09 | 01:39 | 03:09 | 12:00 | 17:22 | 20:13 | 21:43 |
| 31.05.2018 | 01:08 | 01:38 | 03:08 | 12:00 | 17:23 | 20:15 | 21:45 |

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
*Апрель саны, №4 (273)*

Баш мөхәррир: **Сәмигуллин К. И.**
Мөхәррир: **Шафикова Р. Р.**
Дизайнер: **Даутов Р. А.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Сәйфетдияров Р. Г.**
**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur.ru
**Телефон:** +7 (843) 598-09-42

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
**Камил СӘМИГУЛЛИН;**
«Хозур» нәшрият йорты директоры
**Ришат ХӘМИДУЛЛИН;**
ТР МДНнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе
**Нияз САБИРОВ;**
Татарстанның баш казые
**Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
ТР МДНнең Галәмәләр шурасы әгъзасы
**Габдулла ӘДҺӘМОВ**

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**Нәшир:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 нче елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә Заказ №2748
Газетага ярты елга язылу бәясе – 132 сум. Казан шәһәренең мәчетләрендә 24 нче апрельдә таратыла.
График буенча бу санга 23 нче апрель көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.